МӘКТӘП КУШКАНЧА

Быел балаларны укырга әзерләү 20–30 мең сумга төшә

> 15

ЧАКЫРГАЧ БАРАСЫ

«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» законга төзәтмәләр кертелде. Аңлатабыз

> 16

ДИНӘ ЛАТЫЙПОВА:

«Үз җырың булып, халык күңелен яуламасаң, онытыласың, төшеп каласың»

> 18

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 107 (29074) | Җомга | 28 июль | 2023 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4 604609 000131

Илдар Мөхәммәтҗанов

АЛТЫН ЧОР

ТАТАРСТАН КЫРЛАРЫНДА – УРАК ӨСТЕ

Татарстанда барлык районнар да уракка төште. Дөрес, бу көннәрдәге яңгырлар эшне бераз тоткарлый тоткарлавын, тик бер тамчы суга тилмергән Җир-ана өчен анысы да бик тансык. Иң мөһиме – артыкка китмәсен дә өлгергән ашлыкларны вакытында җыеп алырга комачауламасын гына, ди аграрийлар. Аларның быелгы уракка нинди кәеф белән кергәнлеген күреп бәяләр өчен, Теләче районы кырларына юл тоттык.

> 6

Ишетми калмагыз

Киләсе елда Казанда узасы БРИКС (биш дәүләт – Бразилия, Россия, Һиндстан, Кытай һәм Көньяк Африка республикасы берлеге) Уеннары 12–23 июньдә булачак. Россия спорт министры Олег Матыцин әйтүенчә, ярышларны спортның 25 төре буенча үткәрү күздә тотыла. Исегезгә төшерәбез: май аенда Россия Президенты Владимир Путин Министрлар Кабинетына илдә БРИКС спорт уеннарын оештыру һәм үткәрү буенча тәкъдимнәр әзерләргә кушты. Олег Матыцин әйтүенчә, бу уеннар ниндидер ярышларны алыштырмый һәм халыкара спорт календарен да бозмый. Ярышларны Казанның 12 спорт корылмасында уздыру күздә тотыла.

Түбән Кама шәһәрендә газ шартлаган йортны төзекләндерүгә керешкәннәр. Белгечләр әйтүенчә, янгын булган подъезддагы фатирларның барысын да яңартырга туры киләчәк. Күрше подъездларда яшәүчеләр исә, фатирлары җентекләп тикшерелгәннән соң, әкренләп кенә үзләренең торагына әйләнеп кайта башлаган. Тугызынчы подъездга – тулысынча, җиденчегә яртылаш кына күченгәннәр әле. Бинаны бетон белән ныгытачаклар. Моның өчен 90 кубометр чамасы материал китерелгән. Исегезгә төшерәбез: 25 июль иртәсендә Вахитов проспектындагы йортта, көнкүреш газы шартлап, янгын чыкты. Белгечләр фаҗигането сәбәпләрен ачыклый. Шәһәр мэры Рамил Муллин әйтүенчә, зыян күргән фатирларда яшәүчеләрнең һәммәсенә тиешле ярдәм күрсәтеләчәк.

Республикада июль азагына кадәр яңгырлы, эссе һава сакланачак. Ял көннәрендә, киләсе атна башында да безне шундый ук һава торышы көтә. Гидрометеоүзәк мәгълүматларына караганда, шимбә – 29 июльдә урыны белән яшенле яңгырлар, боз, кыска вакытлы көчле җил булырга мөмкин. Көндез термометрның терекөмеш баганасы +31...+36 градуска кадәр күтәреләчәк. Төнлә +15...+22 градус. Якшәмбе – 30 июльдә дә урыны белән көчле яңгырлар явып үтәчәк. Секундына 17–22 метрга кадәр тизлектә көчле җил, боз явуы бар. Көндез һава температурасы +26...+31 градус чикләрендә тирбәләчәк. Төнлә +17...+22 градус. Дүшәмбе – 31 июльдә һәм сишәмбе – 1 августта да яңгырлы, эссе һава буласын фаразлыйлар. Көндез +24...+29, көнчыгыш районнарда +33 градуска кадәр.

Татарстанда «Мәк-2023» операциясенә йомгак ясадылар. Хокук сакчылары наркотиклы үсемлекләр үсеп утырган 100дән артыграк урынны (барлыгы 6,1 мең кв. м мәйданда) ачыклап, юкка чыгарган. Тыелган үсемлекләрнең гомуми авырлыгы 640 килограммнан артып киткән. Моннан тыш, үсемлектән ясалган 2,3 килограммнан күбрәк наркотик, шул исәптән 2,3 кило чамасы марихуана һәм 73 грамм гашиш законсыз әйләнештән алынган. Кырын эшкә катнашы булган 158 кешенең эзенә төшкәннәр. Шуның 146сы – административ, 12се җинаять җаваплылыгына тартылган, дип хәбәр итә Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәте.

ЕРАК ТҮГЕЛ АФРИКА

Авыл хуҗалыгы өлкәсендә, шул исәптән ашлык белән тәэмин итүдә хезмәттәшлек. Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнехановның «Россия – Африка» икътисадый һәм гуманитар форумы кысасында чит ил вәкилләре белән үткәргән очрашуларында әнә шул мәсьәлә кызыл җеп булып узды.

Рөстәм Миңнеханов Санкт-Петербургта узучы халыкара җыенда катнашты. Форумның пленар утырышына кадәр Татарстан Рәисе берничә очрашу да үткәрде. Аерым алганда, Рөстәм Миңнеханов Мавритания Премьер-министры Мөхәммәд Улд Билал, Ангола тышкы эшләр министры Антониу Тете, Тунис тышкы эшләр министры Нәбил Әммар белән күреште.

Мавритания Премьер-министры белән очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов Африканың табигый байлыклары һәм эшче көчләре ягыннан үзенчәлекле ил булуын билгеләп үтте. «Континентның дөнья икътисады һәм халыкара мөнәсәбәтләр мәйданында тоткан урыны артканнан-арта», – диде Рәис. Шуңа күрә үзара хезмәттәшлекне үстерү дә мөһим мәсьәләләрнең берсе булып тора.

Ангола исә – Нигериядән соң, Африкада иң күп нефть җитештерүчеләрнең берсе. «Безгә әлеге юнәлештә хезмәттәшлек итү мөмкинлекләрен карарга кирәк», – диде Рөстәм Миңнеханов Антониу Тете белән очрашуда.

Нәбил Әммар белән сөйләшкәндә, Рәис 2018 елда бу илдә булуын да искә төшерде.

– Без Туниска нефть химиясе һәм машина төзелеше продукциясе, шул исәптән суднолар, автомобиль шиннары, медицина җиһазлары, авыл хуҗалыгы продукциясе озату эшен җәелдерергә телибез. Чит илдән яшелчә, җиләк-җимеш, диңгез ризыклары кайтарту да кызыксындыра, – диде Рөстәм Миңнеханов. Сүз уңаеннан, агымдагы елның беренче чирегендә ике арада товар әйләнеше 20 миллион доллар тәшкил иткән. Татарстанда Тунистан 75 студент белем ала.

Форум кысасында узган барлык очрашуларда да агросәнәгать комплексында хезмәттәшлек мәсьәләләре каралды. «Әйе, бу илләрдә азык-төлеккә, ашлыкка, бездә җитештерелә торган озак вакыт сакланучы продукциягә ихтыяҗ бар. Әлеге илләр студентларын авыл хуҗалыгы юнәлеше буенча укытырга һәм әзерләргә дә кирәк. Мондый эш алып барыла инде, ул алга таба да дәвам иттереләчәк. Рөстәм Миңнеханов бүген барыбызга да эшне көчәйтергә, эшче төркемнәр, шулай ук тармак министрлары җитәкчелегендә республика делегацияләрен оештырырга кушты. Африка континентындагы үзебезгә кызыклы булган илләргә барачакбыз», – диде Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров.

Министр билгеләп үткәнчә, хәзерге вакытта төп мәсьәләләрнең берсе – логистика.

– Африка континенты зур. Мисыр кебек якынрак урнашкан илләр дә, ерактагылары да бар. Ничек кенә булмасын, бу эш оештырылачак. Якын арада ук «юл картасы»н төзеп, аның нигезендә эшкә керешәчәкбез, – диде ул.

Әлеге илләр белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе бар инде. Марат Җәббаров мисалга Мисырны китерде.

– Нигездә, бу – ашлык экспорты. Күләме аз, әмма эш бара. Быел ул логистика аркасында туктап та торды. Ләкин бу эшне дәвам иттерәчәгебезгә ышанабыз, – диде ул.

Форум кысасында Казан вертолет заводы санитар һәм башка вертолетлар да тәкъдим итте. Исегезгә төшерәбез: быел май аенда Татарстан Зимбабвега 12 «Ансат» вертолеты озатты. Алар Африка дәүләтенең төп медицина ярдәме күрсәтү авиациясенә керә.

Санкт-Петербург губернаторы Александр Беглов белән очрашу барышында Рөстәм Миңнеханов төньяк башкалада яшәүче милләттәшләребезгә ярдәм күрсәтүләре өчен дә рәхмәт әйтте.

– Санкт-Петербург – безнең өчен зур сату базары. Татарстан да сезнең җитештерүчеләр өчен кызыклы, – диде Рәис. – Шәһәр хакимияте безгә барлык мәсьәләләрдә дә теләктәшлек күрсәтә. Без татар иҗтимагый оешмаларына ярдәм итүегез өчен дә рәхмәтле. Санкт-Петербургта 20 меңләп татар яши.

«Россия – Африка» икътисадый форумының беренчесе 2019 елның октябрендә узды. Бу ике ил тарихында тәүге шундый зур чара иде. Быел җыенда Африка континентына керүче 54 илнең 49ы катнашу теләген белдергән. 17 ил иң югары дәрәҗәдә – дәүләт башлыклары, 5 ил – вице-президентлары, 5 ил Хөкүмәт һәм парламент җитәкчеләре дәрәҗәсендә тәкъдим ителгән. Чараның пленар утырышында Россия Президенты Владимир Путин чыгыш ясады.

ТЫЛМАЧ ТА КИРӘКМИ

Ислам бизнесы, Түбән Кама шиннары һәм «Рубин» футболкасы. Россиягә эш визиты кысасында Татарстанга Сенегал республикасы Президенты Маки Салл килде. Аралар ерак булса да, без бер-беребезгә чит-ят түгел. Дөньякүләм сәясәтченең Татарстанга сәфәре барышында бу хакта кат-кат әйттеләр.

«Әлеге визит республика өчен зур әһәмияткә һәм кыйммәткә ия», – дип белдерде Татарстан Рәисе Рөстәм Миңнеханов Маки Салл белән Казан Кремлендә үткән очрашуда.

Рәис әйтүенчә, Маки Салл узган ел да Африка берлеге рәисе вазыйфасында Россиягә килгән булган. Сенегал Президенты Украинадагы конфликтны җайга салу мәсьәләсендә дә катнаша: июнь аенда Африка илләре лидерлары делегациясе, шул исәптән Маки Салл да, Киев һәм Мәскәүдә сөйләшүләр үткәрделәр һәм Украинадагы конфликтны җайга салуның «Африка планы»н тәкъдим иттеләр.

Рөстәм Миңнеханов былтыр үзе Сенегалга баруын да әйтте.

– Кунакчыллыгыгыз өчен бик зур рәхмәт. Сенегалда сезнең җитәкчелектә алып барылган эш сокландыра. Уңышларыгызга чын күңелдән шатланабыз, – диде Рәис.

Ике арадагы сәүдә-икътисадый хезмәттәшлеккә килгәндә, ул әлегә зур түгел. Узган елгы саннарга күз салсак, сәүдә әйләнеше 2 миллион доллар тәшкил иткән. Очрашуда билгеләп үтелгәнчә, экспортка йөз тотучы республика буларак, Татарстан Сенегал белән элемтәләрне ныгытырга әзер. Төрле елларда бу илгә республикадан «КАМАЗ» автомобильләре, Казан вертолет заводы продукциясе озатылган булган инде. Бүген дә машина төзелеше, нефть химиясе, авыл хуҗалыгы кебек тармакларда бергәләп эшләргә мөмкин, дигән фикер әйттеләр. Сенегал делегациясе быел «Россия – Ислам дөньясы: KazanForum»да да катнашкан. Рөстәм Миңнеханов Татарстанның ил күләмендә ислам банкингын гамәлгә кертү буенча тәҗрибә мәйданы булуын да искәртте. Фән өлкәсендә дә бергәләп эшләргә мөмкин. Билгеле булганча, республика илнең әйдәп баручы фән үзәкләренең берсе булып санала. Хәзерге вакытта Татарстан вузларында 20 меңнән артык чит ил студенты белем ала. Дөрес, Сенегалдан безгә укырга әлегә нибары 9 кеше килгән.

– Без сезне Татарстанда күрергә һәрвакыт шат, – диде Рәис Сенегал Президентына.

Маки Салл, үз чиратында, илнең әйдәп баручы төбәге буларак Татарстан белән элемтәләрне ныгытырга әзер булуын белдерде.

– 2019 елда ук ниятләгән эш визитын быел тормышка ашыруыма шатмын. Сез Сенегалда 2022 елда булдыгыз, без исә җавап йөзеннән килдек, – диде ул. – Татарстан – мөселман төбәге. Мин 95 проценты мөселманнар тәшкил иткән илне җитәклим. Безнең толерантлык сере дә толерантлык һәм башка диннәр белән үзара дус-тату яшәүдән гыйбарәт. Сездә мәчетләр һәм чиркәүләр янәшә тора. Бу соклануга лаек. Әлеге тәҗрибәне дөньяның барлык илләре дә кабул итеп алырга тиеш.

Сенегал Президенты Татарстанның, бер яктан, үзенчәлекләрен югалтмавын, ә икенче яктан, яңалыкка – нанотехнологияләргә, ясалма интеллектка, санлы технологияләргә омтылуын да мактады.

Казан Кремлендә узган очрашуга кадәр Маки Саллга Казандагы спорт корылмаларына экскурсия үткәрделәр, ул Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркта һәм, республиканың нефть һәм газ химиясе предприятиеләре белән танышу өчен, Түбән Камада булды.

tatarstan.ru

– Сенегал соңгы арада Африкада иң зур спорт чараларының берсе – яшьләр Олимпия уеннарын үткәрергә әзерләнә. Ул 2026 елда узачак. Татарстанның халыкара чаралар үткәрүдә тәҗрибәсе зур. Республика белгечләре Сенегалдагы хезмәттәшләребезгә төрле сораулар буенча, аерым алганда, волонтерлык мәсьәләсендә булыша. Казан кебек төрле юнәлештәге чаралар үткәрү тәҗрибәсе башка беркемдә дә юк, – дип сөйләде Маки Саллның спорт корылмаларына экскурсиясе уңаеннан Татарстан спорт министры Владимир Леонов.

Сүз уңаеннан, чит ил кунагына истәлекле бүләк тә әзерләп куйганнар иде. «Ак Барс Арена» футбол стадионында танылган футболчы, хәзерге вакытта «Рубин-2» тренеры вазыйфасын башкаручы Гөкдениз Карадениз Сенегал Президентына Салл фамилиясе язылган Казан футбол клубы футболкасын бүләк итте.

НИКИТАНЫҢ ҮЗ ПЛАНЫ БАР

Казанның 131 нче лицее укучысы Никита Перов Швейцариянең Цюрих шәһәрендә химия буенча халыкара олимпиадада алтын медаль яулады. Узган ел ул республикада «Ел укучысы» булып танылган иде. Никита быел 11 нче сыйныфны тәмамлады, КФУга укырга керергә җыена.

Ярышта Россия укучылары өч алтын һәм бер көмеш медальгә лаек булган. Алтынга лаек булучылар арасында Никитадан тыш, Мәскәүдән Сергей Росляков, Башкортстаннан Вадим Харисов та бар. Көмеш медаль Алтай краеннан Алексей Михеевка эләккән. Быел Никита Астанада үткән химия буенча 57 нче халыкара Менделеев олимпиадасында катнашып та алтын медаль яулаган иде. Берничә көннән аларны Мәскәүдә зур очрашу көтә.

Никита Перов Швейцариядән әле ике көн элек кенә кайткан. Аны химия укытучысы Әлфия Сафонова, бергә укыган сыйныфташлары каршы алган. Әлфия Сафонова – Никита Перовтан кала, халыкара олимпиадаларда алдагы елларда алтын медаль яулаган Булат Курамшин һәм Руслан Котляровның да остазы. Булат КФУда белем алса, Руслан быел Англиядә Кембридж университетын тәмамлаган.

– Никита кызыксынучан, белемгә омтылучан ул. Тик шул ук вакытта бик тыйнак егет. Сорасаң, җавап бирә, сорамасаң – юк. Ул барлык фәннәрдән дә яхшы укыды. Кайчак, моннысы ничек була, дип мине дә сынап карый иде. Татарча да әйбәт белә. Лаешта яшәүче әбисе аны кечкенә чакта музейларга йөрткән. Менә шуннан да күп нәрсә сеңеп калган, – дип сөйләде Әлфия Сафонова. – Каршы алырга баргач, төп көндәшләр – кытайлар турында да сораштым. «Әлфия Рөстәмовна, алар машина кебек бик җитез», – ди. «И җаныкаем, аларны әти-әниләре 5–6 яшьтән махсус мәктәпләргә җибәрә бит, – дидем. – Син исә атнага ике сәгать химия укып, түгәрәкләрдә шөгыльләнеп, 10 сәгать математика, 8 сәгать физика өйрәнеп, аларны да уздырдың».

Никита 8 нче сыйныфта укыганда, республика күләмендәге бәйгедә икенче урынны алган. 9 нчы сыйныфта илкүләм бәйгедә катнашып, икенче урын алгач, егетне Мәскәү дәүләт университетында да күреп алганнар. Анда очрашуларга чакырганнар, әзерлек курсларына йөргән. 10–11 нче сыйныф укучылары арасында химиядән халыкара олимпиадаларга әзерләнү командасына эләккән. Укыганы әрәм китмәгән. Узган ел алтын медаль откач, 1 миллион сум акча биргәннәр. Быел Менделеев олимпиадасында откан акчага бик кәттә компьютер алган.

Акыллыбашлар Мәскәү, Санкт-Петербург вузларына ашкынганда, Никита үзебезнекен сайлаган. Афәрин! «Чынлап та калдымы?» – дип кат-кат төпченеп сорадым Әлфия ханымнан. «Аның үз планы бар», – диде ул.

Сәрия МИФТАХОВА

Татарстан укучыларының илкүләм олимпиадаларда уңышы

470 катнашучы (узган елгыдан 26 укучыга күбрәк)

40 җиңүче һәм **211** призер (узган елгыдан 14 укучыга күбрәк)

Безнең укучылар тормыш иминлеге нигезләре (ОБЖ), математика һәм технология, экология, хокук буенча илкүләм олимпиадаларда күбрәк катнашкан. Иң күп җиңүчеләр исә технология, экология һәм сәнгать (дөньякүләм матур әдәбият) фәннәре буенча теркәлгән. Призерлар математика, физик культура, экология юнәлешендә күп булган.

Геройлар вакыты

КАЗАНДА ХАЛЫКАРА ДОКУМЕНТАЛЬ КИНО ФЕСТИВАЛЕ УЗДЫ

Казанда халыкара «RT. Док: Время героев» (18+) документаль фильмнар фестивале узды. Тамашачыга махсус хәрби операция геройлары турында 15 фильм күрсәтелде. Әлеге фестивальнең әһәмияте нидә?

Уйдырма урынына – чынбарлык

Оештыручылар белдерүенчә, фестивальнең төп максаты – геройлар турындагы документаль фильмнарны мөмкин кадәр күбрәк кешегә күрсәтү. Бу урында, геройлар дигәндә, хәрбиләр генә түгел, хәрби корреспондентлар, табиблар, волонтерлар, артистлар да күз уңында тотылуын искәртергә кирәк.

– Тормыш хәзер коточкыч тизлек белән үзгәрә, көннән-көн шаккатыра. Миңа калса, хәзер документаль фильмнар нәфис фильмнарга караганда күпкә актуаль. Уйдырма урынына – чынбарлык. Вакыты шундый чөнки. Без геройлар чорында яшибез. Фильмнарыбыз да – алар хакында, – диде ачылыш тантанасында «RT» телеканалының документаль тапшырулар җитәкчесе һәм фестивальнең генераль продюсеры Екатерина Яковлева.

Чынбарлык, димәктән. Фестиваль ачылышында махсус хәрби операциядә катнашучы Хайдер позывнойлы хәрби белән сөйләштек. Безгә күрсәтелгән фильмнарның нинди шартларда төшерелүен сөйләде ул.

– Хәрби корреспондентлар безнең арттан калмады диярлек. Барлык нечкәлекләрне бездән сорадылар, бик куркыныч шартларда да эшләделәр. Шуңа күрә бу фильмнардагы дөреслек һәм «матур картинка» нисбәтен без яхшы чамалыйбыз. Алар андагы хәлләрне ничек бар – шулай күрсәтә, – диде ул.

Киләчәкне уйлап

Әлеге фестивальдәге фильмнарны яшьләр дә күрсен иде. Алар «Кем?», «Ни өчен?» һәм «Нәрсә хакына?» сорауларына җавапны белергә тиеш. Татарстанның вице-премьеры Ләйлә Фазлыева әнә шул фикерен җиткерде.

– Нәкъ менә документаль фильмнар илнең геройларын, илгә дан китергән кешеләрне ничек бар – шулай күрсәтергә, шул рәвешле әлеге ил турында фикер формалаштырырга сәләтле. Моннан тыш, документаль кино – бездән соң яшәячәк буынга мөрәҗәгать итү дә, – диде Фазлыева.

Ачылыш тантанасында сәхнәгә менүчеләр арасында геройлар үзләре – махсус хәрби операциядә катнашучы ир-егетләр дә бар иде. Аларны зал аягүрә басып тыңлады.

– Бүгенге фестиваль киләчәк буынны тәрбияләү өчен нигез булып торсын иде. Балаларыбызда һәм оныкларыбызда ватанпәрвәрлек рухы, дөрес әхлакый кыйммәтләр тәрбияләү өчен, мондый документаль фильмнарны мөмкин кадәр күбрәк төшерергә кирәк, – дип мөрәҗәгать итте кунакларга махсус хәрби операция ветераны, спецназчы Евгений Жемков.

Өч көн дәвамында теләгән һәркем Бәшир Рәмиев исемендәге IT паркта «Казаки» (реж. – Михаил Буров, Олег Некишев), «Пацаны батальона «Восток» (реж. – Олег Некишев, Михаил Буров), «Донбасс 2022» (реж. – Анн-Лор Боннель), «Военкоры» (реж. – Артём Сомов), «Сила» (реж. – Екатерина Китайцева), «Культурный фронт» (реж. – Олег Некишев), «Я ушла на войну» (авт. – Ольга Кирий), «Связь» (реж. – Елена Славянская), «Военкоры-2: птичник и Оля-молодец» (реж. – Клим Поплавский), «Министерство биологической войны» (реж. – Максим Сергеев), «Красная тревога. Гибридная война» (реж. – Анна Чапман), «Священная война» (реж. – Андрей Афанасьев) фильмнарын карый алды.

Фестивальдә Татарстан документалистларының эшләре – «Яңа Гасыр» каналы журналисты Зөфәр Дәүләтшинның Татарстан хәрбиләре турындагы «ZV», Елена Левинның Бөек Ватан сугышы геройларына багышланган «Незабытые» һәм Равил Мөэминовның махсус хәрби операция геройлары турындагы фильмнар циклы да күрсәтелде. Моннан тыш, чара кысасында төрле темаларга «түгәрәк өстәл»ләр һәм фикер алышулар да узды.

Лилия ГЫЙМАЗОВА

Фестивальнең матбугат хезмәте

Әлеге фестиваль февральдә Мәскәүдә узып, бик зур кызыксыну уятты, ди оештыручылар. Шуңа күрә аны төрле шәһәрләрдә уздырырга карар кылынган. Казаннан соң чиратта – Санкт-Петербург, Иркутск, Курск, Волгоград һәм Грозный шәһәрләре. Сүз уңаеннан, чараны «Russia Today» телеканалы оештыра. Казанда исә ул Татарстан Хөкүмәте, Республиканың матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы һәм Татарстан Мәдәният министрлыгы ярдәме белән узды.

КОТЛЫЙБЫЗ!

Республиканың массакүләм мәгълүмат чараларын үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен «Яңа Гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыяте генераль директоры **Әминов** Илшат Юныс улы **«Дуслык» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә зур өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте, актив иҗтимагый һәм хәйрия эшчәнлеге өчен В.Д. Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционер җәмгыяте генераль директоры **Мәганов** Наил Өлфәт улы; республикада гражданлык хәле актларын дәүләт теркәвенә алу системасын үстерүгә һәм камилләштерүгә мөһим өлеш кертүе, дәүләт хакимияте органнарында күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Гражданлык хәле актларын теркәү идарәсе башлыгы **Нигъмәтуллина** Гөлшат Рәдиф кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

Әйтеп кенә бактым

Ике алма

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

– Габделбәр, бүген минем урынга кизү тора алмыйсыңмы?

– Ярар. Бәясен беләсең – ике алма.

«ВТ»ның иң өлкән журналистларының берсе ул Габделбәр Ризванов. Нинди генә гозер белән мөрәҗәгать итмә: «Ярар!» – дип кенә тора һәм: «Бәясе – ике алма», – дип өстәргә дә онытмый. Беркөнне мине машинасы белән бакчага илтеп куйды, икенче көнне килеп, эшкә алып китте. Казанга кайтканда Биектау кибетенә кереп, өрекле, кара җимешле пирог алдым да Габделбәргә: «Хатының Асия белән кара-каршы утырып чәй эчәрсез», – дидем. Алмый гына бит: «Ике алма бирсәң, шул җиткән», – ди. Бер-беребезгә үпкәли башладык, талашып китә яздык.

Мин: «Габделбәр, без синең белән хезмәттәшләр генә түгел, университет буенча сабакташлар да, бер-беребезне инде ярты гасырдан артык беләбез. Шул илле өч елга бер мәртәбә дә пирог алып бирергә хакым юкмыни?» – дигәч, башта аптырап калды бу, аннан икебез дә көлә башладык. «Габделбәр, – мин әйтәм, – хезмәт күрсәткән өчен бәяң ни өчен ике алмадан артмый?» «Бушка килгән әйберенең бәрәкәте булмый, диләр бит. Шуңа күрә «бизнес»ыма «ике алма» дип такса куйган булдым инде кызык өчен генә. Бөтен нәрсә түләүле заман бит!» – дигән була Габделбәр. Әйе, без әнә шулай шаярткан булабыз. Ә асылда бер-береңә ярдәм итәргә атлыгып тору тәрбиядән, заман тәрбиясеннән килә.

Без яшь чакта: «Аз рәхәткә, күп михнәткә түзә адәм баласы...» – дип җырлап, урам әйләнә идек. «Михнәт» дигән сүз телгә, җырга каян килеп кергән диген! Сугыш тәмамланып, дүрт кенә ел узгач тусак та, бернинди михнәт күрмәдек без, ачлы-туклы яшәмәдек. Мичтә тәгәрәткән я ярып пешерелгән бәрәңгедән, тары боткасыннан, өстенә юка гына итеп май ягып, бераз шикәр комы сипкән мич ипиеннән тамак туя иде. Хәер, ул чакта ризыкны сайлап алу мөмкинлеге дә булмады инде аның.

Беркөнне бакчада карбыз ашап утырабыз. Тугыз яшьлек оныгым Кәрим: «Дәү әти, карбыз төшен йотсаң, эчеңдә карбыз үсәчәк, дип бала чакта сезне дә куркыталар идеме?» – дип сорап куйды. «Кечкенә вакытта безгә карбыз эләкмәде шул, улым», – дигәч, бик аптырады. «Ничек инде эләкмәде?» – ди. «Менә шулай, авыл кибетендә карбыз юк иде, аның өчен Казанга барып йөреп булмый бит инде, акча да әллә ни юк иде, улым». Кәрим зурларча итеп: «Да, были времена», – дип куйды да аннан соң ашап бетергәнче берни дә дәшмәде, соңыннан хатыным Фәридәдән: «Дәү әни, син дә дәү әти шикелле хәерче идеңме?» – дип сораган. Көлә-көлә эчләр катып бетте. И сабыем, сине нинди тормыш сынаулары, нинди язмыш көтә икән инде?! Кәрим әйткәннәрне Габделбәргә дә сөйләдем, без әкрен-әкрен тормыш фәлсәфәсенә кереп киттек. Кешене, яхшымы ул, яманмы, гыйбрәт тәрбияләвен беләбез, бу яктан җеннәребез килешә. Ә менә гыйбрәтләр ничек барлыкка килә, алар үзләреннән-үзләре туамы, әллә монда кеше кулы уйныймы? Габделбәрнең ике алма өчен кемгәдер яхшылык эшләве нәрсә? Хикмәт бушлай килгән нәрсәнең бәрәкәтсез булуында гынамы? Хезмәттәшемнең эшне ике алма белән бәяләве бизнеска пародия сыман инде, ә асылда без – җәмгыятьнең бер чоры җимешләре. Габделбәр әйтмешли, күпмедер дәрәҗәдә юклык заманы безне кеше хәленә керергә өйрәтте. Мин, тормыш һәр кешегә бер алдын, бер артын күрсәтергә тиеш, димим, яшәү көннән-көн әйбәтләнә барсын, тик кеше юләрлеге белән ачы гыйбрәт татырга туры килмәсен иде. Гаилә – җәмгыятьнең бер күзәнәге, диләр. Безнең «ВТ» редакциясе дә бер гаилә кебек. Бездә әби-бабай, әти-әни, балалар һәм оныклар бар. Әмма яшь аермалары төрле булса да, кеше хәленә керү – беренче урында. Димәк, бәндә баласын заман гыйбрәтләре генә түгел, үзебез үк тудырган мохит тә тәрбияли. Үз «өебез»дә безгә рәхәт, уйлар, омтылышлар уртак, вакытлар «алмашып» шаярышкан да булабыз.

Мин җае чыккан саен Габделбәргә: «Алма бизнесың ничек бара?» – дип төрттерәм. Беркөнне ул Разил Вәлиев шигыренә җырланган «Бер алманы бишкә бүләек» җырының бер куплеты белән җавап бирде. Ул җырны мин дә беләм һәм уйга баткан чакларымда шыңшып куям.

Шатлык килде, кайгы төште...
Бәхетләр соң кем өлеше?..
Бәхет булып алма пеште –
Бер алманы бишкә бүләек.

Сез дә көйләп куегыз. Ул халык көенә җырлана бит. Бәхет алмаларын бүлешеп кенә яшәргә язсын иде.

ГЫЙБРИЛӘР ҮЗАРА СУГЫШЫРМЫ?

Дөньякүләм турбулентлык фонында Израильдәге соңгы көн вакыйгалары аерым игътибар сорый. Эш шунда: быел яздан башлап гыйбриләр зур фетнә һәм гыйсъянчылык шартларында яши. Биньямин Нетаньяху – илнең Премьер-министры, суд реформасы үткәрергә карар кылганнан соң, Америка штыкларында утыручы бу ясалма дәүләттә зур ризасызлык дулкыны җәелде.

Яңа гына Кнессет (парламент) «җитәрлек акыл принцибы» дип аталган кагыйдәне гамәлдән чыгарды һәм урамнарда хәл тагын кискенләште. Сәясәт белгечләре хәтта илне гражданнар сугышы хәленә якынлаша дип белдерде. 1948 елда Фәләстыйн җирләрен талап һәм яулап алу хисабына барлыкка китерелгән Израиль болай да бик тыныч яши алмады. Гарәпләр белән даими конфликт гыйбриләргә тыныч йокларга мөмкинлекне бик бирмәде. Соңгы җитмеш елда Израильнең гарәп дәүләтләреннән өстен чыгуының берничә сәбәбе бар иде. Төп сәбәп: Беренче Бөтендөнья сугышыннан соң хәлифәлекне югалткан мөселманнар Көнбатыш державаларына колониаль бәйлелеккә төште. Фәләстыйн, мәсәлән, Англия кулы астында калды. Капиталистик державалар, «бүлгәлә һәм хакимлек ит» принцибына нигезләнеп, гарәпләрне вак дәүләтләргә бүлгәләп бетерде һәм аларда курчак хөкүмәтләр урнаштырдылар. Алжир, әйтик, Франция коллыгыннан 1960 нчы елларда гына котылды дип санала. «Санала» дип шуның өчен язам, чөнки рәсми рәвештә бәйсезлек алсалар да, колонияләр Көнбатышның идеологик һәм сәяси басымы астында яшәделәр, финанс бәйлелегендә тордылар. Бу катлаулы темага артык тирәнәймичә генә, шуны искәртик: Израиль көнбатышлылар тарафыннан Якын Көнчыгышны кулда тоту өчен плацдарм буларак барлыкка китерелде, бүгенгә кадәр Американың хәрби һәм финанс ярдәме белән яши.

Израильгә каршы көрәшүче ике көч бар: берсе – гарәпләр, икенчесе – ортодоксаль яһүдләр. Игътибар итегез: мин беренче көч турында «мөселманнар» димәдем, «гарәпләр» дип гомумиләштердем. Фәләстыйнда гыйбриләргә каршы көрәшүче гарәп төркемнәре арасында мөселманнар да, коммунистик хәрәкәт тарафдарлары да, христианнар да, демократияне яклаучылар да бар. Хәзерге вакытта төп көчне ислам каршылыгы тәшкил итә, әлбәттә, әмма көрәш алып баручы мөселманнар – төрле секта әһелләре, үзара бердәмлек юк. Тагын бер нәрсәне искәртик: Фәләстыйнны азат итү өчен көрәшне гарәп дәүләтләре түгел, төбәктәге дәүләти булмаган төркемнәр генә алып бара. Вазгыять шулай корылган: гарәп илләренең җитәкчеләре бу көрәшне якламыйлар.

Гыйбриләрнең Фәләстыйнда куәтле дәүләт буларак берләшүләре Коръәннең 17 нче «Әл-Исра» сүрәсендә вәгъдә ителә. Аллаһы Тәгалә бу халыкка ике тапкыр көч-куәт биреләчәген һәм икесендә дә аларның Җир йөзендә бозыклык таратачакларын һәм ахыр чиктә хурлыклы рәвештә тар-мар ителәчәкләрен сөйли. Үзләренә җибәрелгән пәйгамбәрләрне үтерүләре гыйбриләрнең беренче бозыклыгы булып санала. Шул бозыклыкның бер дәлиле – алар тарафыннан үтерелгән Яхъя пәйгамбәрнең башы Дәмәшкъ шәһәрендәге өммәвиләр мәчетендә махсус сандыкта саклана. Сүриягә визиты вакытында Путин ул мәчеткә керде, сандыкны карады. Мәгълүмдер ки, пәйгамбәрләр тәне бозылмый, бәләзмәләүне таләп итми. Беренче җиңелү безнең эрага кадәр булып, гыйбриләрнең дөнья буйлап гасырлар буе сөрелеп йөрүләре, дәүләтсез яшәүләре, бары тик 1948 елда гына, Аллаһның вәгъдәсе тормышка ашырылып, икенче тапкыр куәткә ирешүләре – тарихи фактлар. Икенче тапкырында да бозыклык таратулары – көн чынбарлыгы. Бүген бөтен дөньяда ЛГБТ хәрәкәте өстенлеккә ирешергә омтыла, зәңгәрләр һәм алсулар диктатурасын урнаштырырга телиләр икән, бу асылда сиончылар – гыйбри дәүләтен оештыручылар эшчәнлеге нәтиҗәсе. Сион тарафдарларының барлык көнбатыш илләрендә дә йогынтылы булуларын һәм дилбегәне үз кулларында тотарга тырышуларын, төп мәгълүмат чараларның хуҗалары булуларын искә алганда, ЛГБТ идеологиясенең ни өчен шулай Җир шары буйлап иркен таралуын аңлау кыен түгел. Израиль – гомосексуаль мөнәсәбәтләрне 1988 елда ук легальләшергән дөньядагы беренче дәүләт икәнен дә искә алыйк. Иң яңа тарихта бозыклык чишмәсенең каян башлануын аңлау өчен шул да җитә. Россиядә интернет ресурслар күпләп бикләнә башлаганчы, мин гыйбриләрнең рәсми порталларын даими күзәтеп бара идем һәм әйтә алам: илдә җенси бозыклык нигезендә эшләнгән җинаятьләр массакүләм төстә. Юк, зина кылу, бер җенестәгеләрнең бозыклыклары турында әйтмим, алар анда җинаять булып саналмый, шулар нигезендә үтерүләр, коллыкка төшерүләр, тән җәрәхәтләре ясаулар турында сүз бара.

Ахырзаман пәйгамбәренең хәдисләре Фәләстыйнның кыямәт алдыннан азат ителәчәген, Әл-Кудска (Иерусалимга) яңадан мөселманнар хуҗа булачагын хәбәр итә. Бу хәдисләрне гыйбриләр бик яхшы беләләр. Фәләстыйнда алар гаркад агачыннан урманнар үстерделәр, чөнки хәдисләрнең берсендә гыйбриләрне бары тик гаркад агачы гына үз артына яшерәчәге хакында мәгълүмат бар. Мин хәтерлим әле: Израиль генераллары 2005 елларда гаркад агачы утыртканда: «Бу агачлар киләчәктә безне саклаячак», – дип әйтәләр иде.

Израиль дәүләтенә каршы көрәшүче икенче көч – ортодоксаль яһүдләр, чөнки алар, Машиах (гыйбри мессиясе) чыкканчы, гыйбриләргә үз дәүләтләрен төзергә ярамый, дип баралар. Бу һәлакәткә китерәчәк дип саныйлар. Андыйларның күбесе Израильдән читтә яши һәм гыйбри дәүләтенә каршы зур манифестацияләр оештыра. Израильнең үзендә яшәүчеләре еш кына гарәп манифестацияләренә теләктәшлек белдерә һәм сиончылар алдында аларның бер абруйлары да юк.

Израильнең соңгы көннәрдә зур сәяси тетрәнүләр кичерүе гыйбриләрнең үзләренә икенче тапкыр бирелгән куәтнең пигын узуларын һәм түбәнгә таба юл тотуларын сөйли. Фәләстыйн каршылыгы белән көрәштә дә алар үзләрен элеккечә иркен тота алмыйлар инде. Басымчаклык һәм башбаштаклык кылу көннән-көн кыенлаша.

Израильнең кыска гомерле дәүләт булып оешуын аның Көнбатыштагы тарафдарлары да яхшы белә. 1967 елда ук Арнольд Тойнби – Халыкара мөнәсәбәтләр король институты директоры, танылган британ галиме, Израиль 60–70 елдан артык тормас, дип фаразлый. Бүген ул куйган чик узып бара инде. Генри Киссинджер – милләте белән гыйбри булган Америка сәясәтчесе 2012 елда гыйбри дәүләтенә тагын ун ел вакыт калуын әйтте. Дөрес, аның ул фикерен фейкларга бай булган Америка газетасы гына бастырды. Әмма барыбер чама чамага туры килә бит. Израиль зур сәяси кризис кичерә, анда хөкүмәт артыннан хөкүмәт алышына, илне берләштерердәй лидер табылмый. Гыйбриләрнең икенче тапкыр тар-мар ителүләре өчен тарихи вакыйгалар өлгереп җитмәде әле. Кешелек дөньясы аңа кадәр бик дәһшәтле вакыйгалар аша үтәргә тиеш. Аянычтыр, ул вакыйгаларның оеткысы салына инде, чүпрәсе кабара. Әлегә Израиль үз куәтен Сүрия күгендә күрсәтә. Америка очкычларына утырган гыйбри пилотлары күпне күргән Шәм җирләрен даими утка тоталар. Израиль разведкасы дөньяның төрле илләрендә сәяси үтерүләр оештыруда беренчелекне бирми. Сәяси ат йөрешләре ясар алдыннан ил лидерлары гыйбри җитәкчелеге белән киңәшә. Дөньяның төрле почмакларында барган конфликтларда гыйбри йогынтысы теге яки бу рәвештә үзен бик еш сиздерә. Әмма кояш баюга таба бара инде. Яңа таң гыйбри таңы булып атарга вәгъдә итми. Алар файдасына бер ялган таң (шайтан таңы) булачак әле ләкин. Яһүд раввиннары шул таңга ышана, аның ату көне якынлаша, дип гел әйтеп торалар.

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

ЮК БАР БУЛМАС

2 миллиард сум. Ел башыннан бирле Татарстанда яшәүчеләр мошенниклар аркасында әнә шулкадәр акчасын югалткан. Күпме генә сөйләп торсалар да, кешеләр кисәтүләргә колак салырга ашыкмый, күрәсең. Хәер, кырыгалдарлар да тик ятмый. Җиңел генә акча эшләүнең әллә нинди яңа ысулларын тәкъдим итәләр. Алдакчылар тозагына эләкмәс өчен, нәрсәне истә тотарга кирәк? «ВТ» хәбәрчесе әнә шул сорауга җавап эзләде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Мошенниклар корбанына әверелмәс өчен, икътисадчы Илгизәр ГАЙНЕТДИНОВтан 5 киңәш

1. Өйдә акча аны тота белгән кеше кулында булырга тиеш. Кайберәүләр турында еш кына: «И саран, акча җәлләүдән башка эше юк», – диләр. Ә бәлки, ул – киресенчә, бик сакчыл кешедер.
2. Ярык тагарак янында утырып калмас өчен, таныш түгел кешеләрдән килгән смс-хәбәрләргә, юмарт тәкъдимнәргә саграк карагыз.
3. Акчаны чит кешегә яки оешмага тапшырганчы, документларын тикшерегез, кертемне нәрсә эшләтергә җыенулары турында белешегез. Рәсми мәгълүматны интернет сайтларыннан да табарга мөмкин.
4. Сезне ашыктыралар яки уйларга вакыт бирмиләр икән – бу да шик тудырырга тиеш.
5. Җиңел килә торган акчага ышанмагыз. Гади кеше болай гына баеп китә алмаячак. Финанс пирамидаларының өске катында утыручылар гына кесә тутырып акча эшли ала. Ә андый «җылы» урыннарны алдан ук алып бетерәләр инде.

«Лотереяда оттым»

Чаллыда яшәүче Артур Мәҗитов ничек алданганын үзе дә сизмичә калган.

– Интернет-кибеттән шактый зур суммага көнкүреш техникасы сатып алдык. Озак та үтмәстән: «Сатып алучылар арасында лотерея үткәрдек, сез – җиңүчеләрнең берсе», – дип шалтыраттылар, – дип сөйли Артур. – Шикләнер иден, исем-фамилиямне, телефон номерымны да беләләр бит. Имеш, тикшереп карау өчен, минем телефон номеры буенча 50 мең сум акча күчерәчәкләр. Мин шуны кире җибәрәм дә, миңа отыш – 200 мең сум акча киләчәк. Картага, чыннан да, 50 мең сум акча килеп төште. Ярар, алдасалар алдарлар, 50 мең сум акча барыбер минеке түгел бит дип, аны тиешле номер буенча күчердем. Шуннан соң бүләгем дә, шатлыклы хәбәрне җиткергән администратор да юкка чыкты. Ә телефоныма таныш түгел ир-ат шалтыратып, минем исемгә микрозаем рәсмиләштерелүен һәм картадагы акчаны алты ай эчендә кире кайтарырга кирәклеген әйтте.

Татарстан буенча Россия Эчке эшләр министрлыгының матбугат хезмәтеннән алынган мәгълүматларга караганда, ел башыннан бирле республикада яшәүчеләр мошенникларга 2 миллиард сумнан күбрәк акча күчергән. Кырыгалдарлар кармагына күбрәк өлкән яшьтәгеләр эләгә, ди хокук саклаучылар. Әле шушы арада гына Казанда яшәүче 79 яшьлек карчык инвестицион кертем вәгъдә иткән алдакчыларга ике атна эчендә 4 миллион сум акчасын күчергән.

Татарстан буенча Эчке эшләр министрлыгында соңгы арада төп башына утыртуның иң еш күзәтелгән ысулларын да әйттеләр. Болар – акчаны инвестицияләү, банк картасына һөҗүм итәргә тырышучылардан «коткару» һәм якыннарның бәлагә таруы. «Халык телефоннан үзен банк хезмәткәре дип таныштырган мошенникларга тиз ышана. Аларга бар булган акчасын гына күчереп калмыйча, банк картасы турындагы мәгълүматны, телефонга килгән смс-кодларны да әйтәләр. Шул рәвешле, кырыгалдарлар чит кешегә кредит та рәсмиләштереп куя. Нәтиҗәдә халык акчасыз гына түгел, банк алдында бурычлы да булып кала», – ди хокук саклаучылар.

Җиде кат уйла

Казан дәүләт аграр университеты доценты, икътисадчы Илгизәр Гайнетдинов фикеренчә, мошенниклар бик ышандырырлык итеп алдый. Алданучыларны бу гына акламый, билгеле.

– Әгәр сез шул ук инвестиция ярдәмендә акча эшләргә уйлагансыз икән, иң элек мәсьәләне җентекләп өйрәнергә кирәк. Банк системасында төрле продуктлар бар. Акчаны лицензияле оешмаларга керткән очракта да, уяу булырга киңәш итәлә. Мәсәлән, пайлы инвестиция фондына йөз мең сум акча салырга уйладыгыз ди. Бу очракта беренчел кертем рәвешендәге акча югалмыймы? Мин шәхсән иң элек шуның белән кызыксыныр идем, – ди белгеч. – Әгәр син кулдагы артык акчаңны югалтырга риза икән, бәхетеңне сынап карый аласың. Әмма соңгы акчаны бер белмәгән кешегә тапшырганчы, җиде кат уйларга кирәк.

Рәсми мәгълүматларга караганда, ел башыннан бирле илдә финанс пирамидалары саны, узган елның шушы ук чоры белән чагыштырганда, 20 процентка арткан. Белгечләр 2449 шикле оешманың эзенә төшкән. Аларның 58 проценты криптовалютага бәйле.

Илгизәр Гайнетдинов әйтүенчә, мошенникларга карата законнарның артык кырыс булмавы да аларның саны артуга китерә.

– Үзебез үк күреп торабыз бит: «Финико» финанс пирамидасыннан ничәмә-ничә кеше зыян күрде, тик эзәрлекли башлагач, оештыручылар гади халыктан җыйган акча белән чит илгә чыгып качты да югалды. Мошенниклыкта гаепләнүчеләрнең бездә калган күчемсез милкен сатып, зыянны азмы-күпме каплау эше дә акрын бара, – ди белгеч.

Дивандагы эш

Җиңел юл белән акча эшләү ысулларының берсен «ВТ» хәбәрчесе дә тикшереп карады. «Ватсап»ка таныш түгел номердан килгән смс-хәбәргә ышансаң, өйдән чыкмыйча гына да аена 360 мең сумга кадәр акча эшләргә мөмкин икән. Кызыкмаган җирдән кызыгырсың. Эше дә чүп кенә. Онлайн кибетләрдәге товарларның фотоларын карап утырырга кирәк. Һи, бүгенге интернет заманында акча түләмәсәләр дә бик яхшы башкарабыз без бу эшне. «Акча эшләргә теләсәгез, «берле» төймәсенә басып, җавап җибәрегез», – дигәннәр смс-хәбәрдә. Шулай эшләдем дә. Ун минут та үтмәде, үзен Алена дип таныштырган «ярдәмче» яза. Баксаң, диваннан тормыйча гына аена 30 мең сумнан 360 мең сумга кадәр акча эшләп була икән. Интернетта кайчан теләсәң, шунда утырырга мөмкин. Әмма бер шарт бар: эшкә тотынгачы ким дигәндә ун мең сум күләмендә взнос яки беренчел кертем түләргә кирәк. Махсус счетка күбрәк акча күчергән саен, зуррак хезмәт хакы алу мөмкинлеге дә артачак, имеш. «Түләгән акчагызны бер ай эчендә артыгы белән кире кайтара алачаксыз», – дип тә үсендерергә тырыша Алена. Шуннан артыгын язышмадык. Аленаның телефон номерын «кара» исемлеккә озаттым. Бу – мошенникларның чираттагы тозагы икәне аңлашыла, әлбәттә.

– Моның ише «эш тәкъдим итүчеләр» бер үк төрле схема буенча эшли, – дип кисәтә ВТБ банкының цифрлы бизнес департаменты җитәкчесе Никита Чугунов. – Алар, күбрәк кеше җәлеп итеп, мөмкин кадәр тизрәк акча савып калырга тырыша. Гомумән, интернетта эш эзләгәндә сак булырга кирәк. Таныш түгел кешеләр белән аралаша башлаганчы, смс-хәбәр килгән телефон номерын рәсми чыганаклар аша тикшерергә киңәш итәбез. Еш кына мондый шалтыратулар чит илдән килә. Шуңа күрә интернетта күпмедер акча эшләп өлгерсәгез дә, «хезмәт хакы»гызны барыбер ала алмаячаксыз.

Россия Үзәк банкы исә кырыгалдарларның тагын бер яңа «кәсебе» турында да әйткән. Баксаң, соңгы арада онлайн уен рәвешендәге финанс пирамидалары саны арткан икән. Интернетта криптовалюта белән эш итәргә өйрәнәсең дә соңрак чынбарлыкта нәкъ шундый бизнес корасың, янәсе. Тик мондый уенның нәрсә белән тәмамланачагы көн кебек ачык.

Гаепсездән гаепле

Казанда яшәүче Лилия Сафина да мошенниклар корбанына әверелгән. Тик үзен түгел, ә аның исеменнән башкаларны алдаганнар.

– Гаиләбез белән Дагыстанга бардык. Ял иткәндә төшкән фотоларны социаль челтәрләргә урнаштырып бардым. Кырыгалдарлар әнә шуннан оста файдаланган. Социаль челтәр белән бергә электрон почта тартмасын да «ватып», интернетка минем исемнән игълан язганнар. Имеш, ялда авариягә эләгеп, кызыбыз үлем хәлендә ята, аңа операция ясау өчен ашыгыч рәвештә 500 мең сум акча кирәк. Ышандыру өчен, социаль челтәргә электрон почта тартмасында сакланган паспорт һәм баланың туу турындагы таныклыгы нөсхәсе фотоларына кадәр урнаштырганнар. Хәерчегә җил каршы дигәндәй, таулар арасында телефоным тотмаган. Бер кичтә шактый туганнарым, якыннарым мошенникларга акча күчерергә өлгергән. Арада 10–15 мең сум күчерүчеләр дә бар. Бу эшкә бернинди катнашым булмаса да, кеше алдында үземне гаепле хис итәм, – ди Лилия.

«Сбербанк» мәгълүматларына караганда, илдә яшәүчеләргә мошенниклар тәүлегенә уртача 8,6 миллион тапкыр шалтырата яки смс-хәбәр юллый. Чагыштыру өчен, былтыр әлеге сан күп дигәндә 5 миллионны тәшкил иткән.

Эльвира ВӘЛИЕВА

«Җиңел юл белән баерга тырышу – хәрам»

Тимур хәзрәт КАМАЕВ, «Ирек» мәчете имам-хатыйбы:

– Кешенең «нәфес» дигән әйбере бар, ул һәрвакыт җиңел юл белән баерга тели. Акча дип күз акайгач, акылны эшкә җигәргә дә авыр. Имеш, син акчаңны билгесез затларга бирәсең дә, алар сиңа аны утызар процент белән кайтара. Акылсызлык бит бу. Соң алар шул ук сумманы банктан да алырга мөмкин бит. Сиңа вәгъдә иткән зур процентларны да түләп торасы булмаячак. Бер генә кредит оешмасында да бу кадәр зур ставка юк. Мошенниклар кармагына эләгү халыкта финанс белеме булмаудан килә. Мәктәптә хокукларыбызны да өйрәтмиләр бит. Ни өчен икәне дә билгеле. Сарык көтүен идарә итү җиңелрәк. Әмма шәригатебез безне бөтен яктан саклый. Коръәннең «Бәкара» сүрәсендә әҗәткә акча алу турында бер битлек аять бар. Башка андый озын аять юк. Анда әҗәткә алганда-биргәндә шаһитлар булсын, диелә. Биредә расписка мәсьәләсе дә күтәрелә. Дуслар булса да, мөселманнар булса да, кешенең нәфесе беркая да китми. Мөселманнарга карата Аллаһы Тәгалә әйтә: «Бурычка акча алганда, ике шаһит булсын», – ди. Ә җиңел юл белән килгән акча ул – хәрам. Аның хәере юк. Ни кылганыңны аңлап, тәүбә итәргә дә, башка мондый адымга бармаска кирәк. Без шуны төшендерергә тиеш. Тик иң әүвәле халыкка динне аңлатырга кирәк. Имансызга күпме тукысаң да барыбер. Ныклы нигез булса гына, аң-белемне кирпеч тезгән кебек өеп була. Нигезе юк икән, күпме тырышсаң да, ул йорт барыбер ишеләчәк.

Сораштыру

Җиңел юл (инвестицияләр, челтәрле маркетинг) **белән акча эшләп караганыгыз бармы?**

- Әйе, тик акчамны гына югалттым............ 8%
- Әйе, шулай табыш алганым бар............ 8%
- Кызыгам, тик куркыта............ 11%
- Юк, мондый нәрсәләргә ышанмыйм............ 73%

«ВТ»ның «ВКонтакте» социаль челтәрендә үткәргән сораштыруыннан

Зөһрә
САДЫЙКОВА

АЛТЫН ЧОР

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Югалту

Районның 25 мең гектардан артык чәчүлек мәйданнары бар. Шуның 6 меңгә якын мәйданына – көзге, 9300 гектарына язгы культуралар чәчелгән. Моннан тыш, рапс һәм көнбагыш, җитен басулары бар. Теләче районында апрельдән башлап нибары 35 мм явым-төшем булган. Соңгы арада исә көн саен 6–20 мм яңгыр яуган.

– Яңгырлар бик кирәк иде, тик алар бер ай алданрак яуган булса, тагын да шәбрәк буласы иде, – диде районның авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы урынбасары Илфар Баев. – Чөнки хәзер инде безгә өлгергән ашлыкның бөртеген дә әрәм итмичә, вакытында җыеп алырга кирәк. Техника әзер, комбайнчылар яңгырлар узып киткәнен зур түземсезлек белән көтеп тордылар.

Ничек кенә булса да, быел аграрийларга яңгырны күпсенү дөрес булмас иде. Шифалы яңгырлардан соң, корылыктан интегеп, тишелеп чыга алмыйча утырган карабодайлар матур гына үсеп киткән, бәрәңге, көнбагыш, рапска җан өрелгән, кукурузлар буй җибәргән, күпьеллык үләннәргә дә өмет баглыйлар.

Алда телгә алган сәбәпләргә бәйле, районда эш башланып кына килә. Уракка да бер-ике хуҗалык кына төшкән, шушы берничә көн эчендә барысы да ныклап тотыначак. Иген басуларына иң беренчеләрдән кереп китүчеләр – «Август-Теләче» агрохолдингы игенчеләре. Билгеле булганча, алар районга өч ел элек килеп эшли башлаган иде. Әлеге вакытта иң зур чәчүлек мәйданнары да аларда. Чәчү мәйданнары 10 мең гектарны тәшкил итә. Басуларында көзге һәм язгы бодай, карабодай, борчак, рапс, җитен үсә. Без исә Үзәк авылы тирәсендәге борчак басуларында барган эшне күзәттек.

– Узган ел игенчеләр өчен бик уңышлы булган иде. Сезонны башлаганда, быел да шундый матур күрсәткечләргә өметләндек. Тик корылык та, суыклар да үз эшен эшләде – уңышны югалттык, – ди генераль директор урынбасары Айдар Габделганиев. – Шулай да быел көзге бодай уңышы сынатмас, дип уйлыйбыз. Узган ел көзгесен дә, язгысын да гектарыннан 50шәр центнер җыеп алган идек. Быел көзге бодай 40 центнер тирәсе булыр. Борчакны исә узган ел гектарыннан 35 центнер алган идек. Быел әлегә 20 центнер гына бара. Яңгырлар үз вакытында бик кирәк иде. Тик хәзер күпкә китсә, ашлыкның сыйфаты югалырга мөмкин.

Вакыт кадере

Иген басуында һәр сәгатьнең генә түгел, һәр секундның кадерен белүчеләр кемнәр икәнен беләсезме? Әлбәттә инде, комбайнчылар. Бу көннәрдә алар чабышка чыккан атны хәтерләтә. Шуңа күрә берәз гына сөйләшеп алырга да чак туктаттык үзләрен. Әнә иң яшь механизатор Денис Алексеев та исәнләшү белән үк ярым шаяртып: «Эш калдырып йөрисез инде», – дип куйды.

– Башта мин Казанда яшәдем. Өйләнгәч, гаиләм белән авылга күченеп кайтып, йорт сала башладым, – диде ул. – Механизаторга авылда бервакытта да эш бетми. Монда эше дә, ашы да, саф һавасы да, торыр җире дә, ирегe дә бар. Шәһәрдә торып, эти-әнигә йөк буласы килми. Бөтен яшьләр авылга кире кайтып бетәчәк. Менә әйтте диярсез әле! Быел мин икенче сезонга чыктым. Эшемне яратам. Узган ел эшләү тагын да кызыграк иде, быел да сынатмабыз, дип уйлыйм.

Яшь комбайнчылар белән беррәттән җирнең дә, хезмәтнең дә, икмәкнең дә кадерен белүче тәҗрибәле механизаторлар да бар. Әйтик, Мәүлитҗан Хәбибуллин быел 35 нче урагына төшкән.

– Басуда эшләүнең үз яме һәм тәме бар, – дип елмая ул. – Без инде шуңа ияләнгән, сезонны көтеп кенә торабыз. Басудан өйгә кайтулары да икенче төрле күңелле. Игенченең хезмәте дә лаеклы бәяләнә, дип саныйм. Хуҗалар эшләгәнне аңлый, кирәк вакытта ярдәм дә итә. Элеккеге кебек тузанлы комбайннарда да эшләмибез. Хезмәт хаклары да яхшы, зарланып булмый. Шул ук вакытта элек эшләгән елларны да яманлыйсы килми. Ул вакытта да сагынып искә ала торган матур мизгелләр күп булды.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Төп максат – булганны вакытында җыеп алу. Чөнки без ашлыкны бала шикелле карап, тәрбияләп үстерәбез», – ди Айдар Габделганиев.

Әлеге вакытта басуларда сигез комбайн эшли. Алар өлгерми башласа, оешманың башка бүлекчәләре ярдәмгә килә. Тик, җитәкчелек әйтүенчә, хуҗалыкларда эшче кадрларга кытлык бар. Генераль директор Алмаз Хәйруллин сүзләренчә, җәйнең ике ае – аграрийларның ел буе эшләгән эшен күрсәтү чоры.

– Хәзер никтер халык комбайнчыны «шабашник», вакытында акча эшләп калучы гына буларак кабул итә башлады. Мин моның белән килешмим. Алар – безгә бик кирәкле кешеләр. Һәм, әлбәттә, хезмәт хаклары да яхшы. Бездә яңа технологияләр, техника булгач, кадрларны да әледән-әле укытып торабыз, – ди ул.

Яңалык

«Август-Агро» кырларының төп үзенчәлеге: культураларны җирне сөрмичә генә утырту. Идарәче компаниянe әлеге технологияне Татарстанда беренчеләрдән булып кулланучы дип әйтеп булмый, тик шундый зур масштабларда эшләүчеләр башка юк. Оешма эшли торган барлык тугыз районда да җир No-till (ноу-тилл) технологиясе буенча эшкәртелә. Айдар Габделганиев аңлатуынча, беренчедән, мондый ысул белән утыртканда җир дымны саклый, уңдырышлылыгы арта. Экология ягыннан да җир өчен файдалы. Ягъни җир катламнарына зыян килми, микроорганизмнар барысы да үз урынында кала. Туфрак катламын җил, кояш киптерми. Углекислый газ азрак оча. Икенчедән, чыгымнар һәм ресурслар ягыннан отышлы. Ягулыкка, техникага, запас частьларга тотылган чыгымнар 30–40 процентка кими.

– Барлык технологиясен саклап эшләгәндә, традицион эшкәртүдәге кебек үк уңыш алырга мөмкин. Кайбер елларны хәтта күбрәк тә алып була. Уңышны җыеп алганнан соң берничә көн узуга ук, шушы җиргә яңа культура чәчелә. Безнең төп максат – корылык елында да әйбәт уңыш алу, – диде ул.

Айдар Габделганиев аңлатуынча, болай итеп эшләгәндә аерым бер шартларны үтәргә кирәк. Беренчедән, культураларны ел саен аралаштырып чәчәләр: рапс – язгы бодай – көнбагыш – көзге бодай. Аларның һәркайсының үз бурычы бар. Кайберләре туфракны йомшарта, икенчеләре тиреләйтә. Бер культураны алгач, икенче елга бераз юнәлешен үзгәртеп, икенче культураны турыга чәчәләр. Мондагы басуларда ашлык төягән «КАМАЗ», бер күреп ияләшкән йөк машиналары да юк. Алар урынына уңышны ындыр табагына зур егәрлекле махсус тракторлар ташый.

Моннан тыш, электрон сервислар барлык кырларны вакытында күзәтеп, эшне планлаштырырга ярдәм итә. Кайда нәрсә чәчелгән, узган ел монда нәрсә үстерелгән, күпме ашлама кертелгән, никадәрле уңыш җыеп алынган, культуралар кайчан тишелеп чыккан һәм ничек үсә, күпмесе җыеп алынган, техника кайда эшли һәм күпме ягулык тотылган, нинди тизлек белән хәрәкәт итә, кайсы комбайнчы никадәр ашлык суктырган, амбарга күпме күләмдә икмәк кайткан. Хәтта тракторчы яки комбайнчының туктап ял итеп алуына кадәр – барысын да кулдагы телефондагы программа аша күзәтергә мөмкин. Оешманың үз метеостанциясе булу да эшне планлаштырырга ярдәм итә.

Киләчәктә «Август-Теләче» җәмгыяте Татарстандагы башка барлык бүлекчәләренә дә югары уңыш бирүчән элиталы орлыклар әзерләячәк. Моның өчен симәнә эшкәртү заводы сафка басып килә. Быел аны ачарга планлаштыралар. Заводка кергәнче кырдан алып кайткан ашлык эшкәртелә, чистартыла, киптерелә.

Икмәк булса, акча да була

«Алан» хуҗалыгында озак еллар эшләүче комбайнчы бар, дигәч, аларга да кереп чыктык. Алар да бүген-иртәгә уракка төшәргә әзер торалар иде. Хуҗалыкның 4 мең гектар чәчү мәйданы бар.

– Без басуларны күздән тиреләйткән идек. Аннан соң иртәрәк чәчү дә корылыкка каршы торырга ярдәм итте. Шуңа күрә уңыш начар булмас дип уйлыйбыз, – диде «Алан» җәмгыяте җитәкчесе Алмаз Фәсхетдинов.

Дүрт комбайнчының берсе Ринат Гатауллин быел 37 нче сезон уракка чыга.

– Урак өсте – бик дулкынландыргыч көннәр ул. Аның һәр минуты кадерле. Аны көтү дә, эшләү дә, соңыннан нәтиҗә ясау да, – диде ул. – Икмәге булса, акчасы да бар. Быел уңыш уртача булыр төсле. Узган елгы кебек мул итеп алып булмас инде. Көзге культуралар яхшы, язгылары бик сөендерми әле. Икмәк мул булганда, эшләргә дә рәхәт. Соңыннан аны табында да: «Үзебез суккан икмәк бит бу!» – дип горурланып ашыйбыз.

Республиканың Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 26 июльгә булган мәгълүматлары буенча, Татарстанда 103 мең гектардан артык җирдә 310162 мең тонна ашлык суктырылган. Уртача уңыш – гектарыннан 29,9 центнер. Иң зур мәйданнар Зәй, Аксубай, Яңа Чишмә, Әлки, Сарман районнарында суктырылган. Уңдырышлылык буенча лидерлар: Тәтеш, Мамадыш, Кайбыч, Чүпрәле, Нурлат районнары.

4 август көнне сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Лилия Гыймазова** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Безгә бүләк нигә юк?

Хатыным белән 1959 елның 19 октябрендә өйләнештек. Быел бергә яши башлавыбызга 64 ел була. Безнең кебекләргә Казанда акча бирәләр дип ишеткән идем. Район кешеләренә түләнми, диделәр. Бөтен кеше Казанга барып язылышырга тиешмени? Андый законны ишеткән юк минем. Ачыклык кертегез әле.

Гаптерәүф МИФТАХОВ.
Саба районы Кече Кибәче авылы

Миләүшә Вакказова, Саба районы Башкарма комитетының ЗАГС бүлеге баш белгече:
– Казан мэриясе чыгарган карар нигезендә 50, 60, 70 ел бергә яшәүче парларга акчалата бүләк бирелә. Бу – Казанда язылышып, шунда яши торган парлар өчен. Безнең районда андый түләүләр каралмаган. 50, 60 һәм аннан да күбрәк ел бергә яшәгән парларны җыеп, матур чаралар үткәрәбез. Социаль яклау бүлеге, мәдәният хезмәткәрләре белән берлектә 1 октябрьдә зурлап Өлкәннәр көне уздырабыз. Озак еллар бергә яшәүче гаиләләрне хөрмәтлибез, аларга бүләкләр бирәбез. Гомумән, ЗАГС бүлеге бернинди түләүләр белән шөгыльләнми. Моның өчен социаль яклау бүлегенә барырга кирәк.

Өченче балага җир биреләме?

Өченче балага җир бирелә иде, хәзер андый нәрсә бармы?

РУЗИЛӘ. Кукмара районы

Татарстан Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының матбугат хезмәте:
– Өч баласы булган, олы баласына 18 яше тулып өлгермәгән гаиләләргә җир бирелә. Әмма 2022 елның җәендә әлеге законга үзгәрешләр кертелде. Аңа кадәр сабыйларының яше туры килгән өч балалы бөтен гаиләгә җир бирелә иде. Хәзер ул бары тик торакка мохтаҗ булганнарга гына тапшырыла. Бу хакта тулырак мәгълүмат алу өчен районның башкарма комитетына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Документларны карап, җир бирелергә тиешме-юкмы икәнен алар хәл итә.

Ничек фатир алырга?

Таныш кызга – 19 яшь, әнисе ата-аналар хокукыннан мәхрүм ителгән. Чит гаиләдә опекун тәрбиясендә үскән. Кыз авылны. Фатир алу өчен нишләргә кирәк? Опекунга, баланы үз исемеңә яздыр, дигәннәр. Бу кыз балага ничек ярдәм итәргә икән? Мондый очракта эшне нидән башларга?

МИЛӘҮШӘ. Казан

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
– Ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга торак бирү тәртибе «Ятим балаларга һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турында»гы 21.12.1996 ел, № 159-ФЗ Федераль закон белән көйләнә. Ятим балаларга 18 яшькә кадәрге, әтисе дә, әнисе дә яки аларның берсе вафат булган балалар керә. Ата-ана хокукыннан мәхрүм ителгән яки эшкә сәләтсез дип танылган 18 яшькә кадәрге балалар караучысыз калган балалар дип санала.

Бу категория гражданнар өчен торак бирү шартлары

1. Баланың күчемсез милке (торак: фатир/шәхси йорт) булмавы.

2. 18 яшькә җитү (һәр төбәктә торакка мохтаҗлар исемлеге формалаша, ятим балалар һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балалар 14 яшькә җиткәч исемлеккә кертелә).

Ятим балаларны һәм ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларны торакка мохтаҗ балалар исемлегенә вакытында кертү һәм исемлекне формалаштыру бурычы опека һәм попечительлек органнарына йөкләнгән. Ятим балаларга һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә гарантияләр турындагы Федераль закон нигезендә, ятим балаларны һәм ата-ана кайгыртуыннан мәхрүм ителгән балаларны муниципалитетлар торак мәйданы белән тәэмин итә.

Фатир алу һәм исемлеккә керү өчен ятим балага документлар җыярга, шулай ук билгеле бер критерийларга туры килергә кирәк.

Төп критерийлар нинди?

– Гражданның ятим яки ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм ителгән бала статусы булырга тиеш;

– гражданга 18 һәм аннан да күбрәк яшь булырга тиеш, әмма шул ук вакытта торакны иртәрәк тә алырга мөмкин;

– гражданның дәүләт ярдәменә мохтаҗ булуы турында рәсми гариза бирелгән булырга тиеш.

Мохтаҗ кеше дәүләт ярдәме алу хокукын тулысынча тормышка ашырганчы фатирга чиратта торачак. Бу мәсьәлә буенча җентекле консультация алу өчен, мохтаҗ кеше исәптә торган опека органына мөрәҗәгать итәргә кирәк.



Илдар Мөхәммәтҗанов

Гөнаһ булмасмы?

Әбиемнең каберендә сиреньнәр үсә, бөтен җирне басып бетерде. Куакны бөтенләй кисеп, чәчәкләр утыртасым килә. Кабер өстендәге агачларны кисү гөнаһ түгелме?

ГӨЛНАЗ. Арча

Тимергали хәзрәт Юлдашев,
«Сәлах» мәчете имам-хатыйбы:
– Агач зур булып үсеп, ботаклары комачаулый икән, аны кисәргә ярый. Зур булып үсми торган агач яки куак, чын чәчәкләр утырту рөхсәт ителә. Пәйгамбәребез (с.г.в.) дә кабергә хөрмә агачының ботагын кадап куйган һәм, шушы хөрмә ботагы кипкәнгә кадәр зекер кылыр, кабер ияләренең гөнаһлары, газаплары җиңеләер, дигән. Әмма мәеткә чәчәк-агачлар түгел, безнең догабыз кирәк.

Ләйсән САФИНА әзерләде

Кайтаваз

«ИРЕМНӘН КУРКАМ» ЯЗМАСЫНА КАЙТАВАЗ

Түзмәскә кирәк, хатын түзгән саен ир шашына гына бара. Беренче тапкыр кул күтәрү белән я шунда ук китәргә, я таба яки уклау белән үзенә тондырырга. Иң яхшысы – өстенә бер чиләк салкын су сибү, шунда ук акылга утырыр иде. Түзә икән – түзсен. Үзе сайлап алган тормыш.

Әнфисә ЗӘКИЕВА

***

Кул уйнаткан ирләрне сугышка, алгы сызыкка җибәрергә кирәк. Алардан юньле нәрсә чыкмас. Төрмәдә ашатып яткырганчы, тегендә файдалары күбрәк булыр.

Дамира ХАНОВА

Сораштыру

Бәрәңгене кайчан алырга?

Бәрәңгене җәй уртасында ук алу гадәткә керә башлады бугай инде. Авылларда иртә өлгерә торган сорт үстереп, бәрәңге казып алучылар шактый. Сабаклары ямьяшел әле, дип сабыр итүчеләр дә күп. Кайбер җирләрдә бәрәңгенең хәтта әле яңа гына чәчәк атып утырганнары да бар, диләр. Быелгы һава шартларында икенче икмәкнең хәле ничек? Бәрәңгедән мул уңыш алу өчен, нәрсәләр эшләргә кирәк? Бакчачыларның хәлен белештек.

Ринат ВӘЛИЕВ,
һәвәскәр бакчачы (Азнакай шәһәре):
– Бәрәңге алырга иртә әле. Сентябрьнең уртасында казырга уйлыйбыз. Бәрәңгенең сабагы корып, 10–15 сантиметрлап калган очракта, көрән төскә керә башлагач, алырга була. Башта яңгыр яумады, соңгы бер ун көн әйбәт койды. Яңгыр бәрәңге чәчәк аткач һәм аннан соң тагын биш көнләп кирәк. Калган вакытта коры булса да ярый. Күршеләрнең бакчасында бәрәңгенең сабаклары гына калган, корт ашап бетергән. Шул корт безгә дә күчә. Бәрәңгене гел карап торабыз. Яфрагыннан колорадо коңгызын, аның личинкаларын чүплибез. Быел әле агу сипмәдек. Утыртканда күзәнәкне генә агулаган идек. Тик файдасы тимәде бугай, колорадо ул препаратка да ияләшкән, күрәсең. Бәрәңгене вакытында карарга кирәк. Үскән чагында төбе формалашсын, сабагы көчлерәк булсын өчен, әйбәт итеп ике тапкыр күмәргә кирәк. Узган елны бер сутый җирдән 54 чиләк бәрәңге алдык. Бер төптән – 8–12шәр эре бәрәңге.

Лилия ХӘСНУЛЛИНА,
блогер (Чирмешән районы Керкәле авылы):
– Безнең бәрәңге өлгерде инде. Яңа уңышны 20 июльдә үк казый башладык. Биш сорт бәрәңге утырттык, икесе – тиз өлгерә торган. Бәрәңгене 25 апрельдә чәчтек. Алсу төстәге, тирән күзлесенең уңышын җыйдык. Бәрәңге өлгергән, кабыгы ныгыган. Бер чиләк орлыктан тугыз чиләк бәрәңге алдык. Шуның чиләктән артыгы гына вак, уңыш яхшы. Өч чиләген орлыкка салып куйдык. Бушаган җиргә аз гына бәрәңге, суган һәм укроп чәчеп куйдык. Иртә өлгерә торган бер чиләк сары бәрәңге дә утырттык. Тик әле ул өлгереп җитмәгән, кабыгы сыдырыла. Шуңа эшне әлегә туктатып тордык.

Мөхәррәм МӨХӘММӘТҖАНОВ,
ветеран-агроном (Буа районы):
– Бәрәңге алырга өч атналап вакыт калып бара. Узган ел 16 августта җыйганбыз. Бу көннәрдә яңгырлар төшкәләве бәрәңгенең төсен үзгәртте. Безнең сабакларда да корт үрчеп килә. Тик алар зыян итми инде. Бу көннәрдәге өлгереше сабак исәбенә дә җитешәчәк.

Иртә өлгерә торган «Ажур» сортын үстереп, өч төптән уңыш алдык. Ул корылыкка чыдам, кышны да яхшы чыга. Бозылганы да, үргәне дә юк. Иң беренче чиратта технология кирәк. Әйтик, бәрәңгене язын җиргә күмеп куеп, көзен вакыты җиткән икән, дип алырга чыксаң, бернинди сорт та ярдәм итми. 3 урынына 5 бәрәңге булырга мөмкин, артыгы түгел. Ә менә аны 13, хәтта 23 итеп бирүдә сортның селекционер салган мөмкинлеге ярдәм итә.

Әлфия МУСИНА,
укытучы (Казан):
– Быел бәрәңгенең уңышы әйбәт булырга охшамаган. Төп сәбәбе – яңгырлар булмау. Бәрәңге утыртканнан соң, бер генә яуды. Дым бөтенләй юк. Җитмәсә, кырау төште. Бәрәңгегә су да сибеп бетерерлек түгел. Апрельдә яңа сорт – иртә өлгерә торган «Беллароза»ны утырттык. Алары әйбәт күренә. Бәрәңге уңышы мул булсын өчен, шактый тырышырга туры килә шул. Сортларын да алмаштырып тору кирәк. Яңгыр яумасмы дигән өмет бар әле, бәлки, аз булса да үсеп китәр.

31 июль | Дүшәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!»16+
09.00, 16.30 «КИТӘМ, ДИМӘ». Телесериал 16+
10.00, 23.30 «УЧИТЕЛЯ». Телесериал 16+
11.00 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
11.30 «Заман көзгесе» 6+
12.00, 22.30 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
14.00 «Соотечественники» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Акыл батл» 0+
16.00 «Переведи!» (учим татарский язык) 6+
17.30 «Трибуна «Нового века» 16+
19.00, 01.15 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Туган авылым» 12+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
22.00 «Реальная экономика» 16+
00.25 «Соотечественники». Александр Славутский. Человек – театр 16+
00.50 «Каравай». От народной музыки до короля инструментов – органа 6+
01.40 «КВН РТ-2022» 16+
02.30 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 16+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Родная земля» 12+
12.05 «Йөрәктән – йөрәккә». Роберт Миңнуллин турында телеочерк 16+
15.30 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Илфак Ибраһимов турында телеочерк 16+
17.30 «Яшьләр тукталышы» 6+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
19.30 «Калеб» 6+
20.00 «Заман көзгесе» 6+
20.30, 02.35 «Таяну ноктасы» 16+
21.25 «Әнисемнең җылы кочагы» 16+
00.15 «Йөрәктән – йөрәккә». Мирхәйдәр Фәйзи турында телеочерк 16+
02.35 «Таяну ноктасы» 16+
03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
03.25 «Йөрәктән – йөрәккә». Татарстанның халык шагыйре Марсель Галиев турында телеочерк (субтитрлы) 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 Светлана Ходченкова, Антон Хабаров, Ирина Пегова. «КАЗАНОВА» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 ПОДКАСТ.ЛАБ «Креативные индустрии» 16+
00.40 «АнтиФейк» 16+
01.15 ПОДКАСТ.ЛАБ «Собрались с мыслями» 16+
01.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Мелодии моей жизни» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Обязательно к прочтению» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Антропология» 16+
03.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Космические истории» 16+
04.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «Психика» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Андрей Мерзликин, Анна Михалкова, Сергей Маковецкий, Ирина Пегова, Виктор Сухоруков. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Пётр Рыков, Мария Андреева, Ольга Кабо, Полина Филоненко, Юрий Ицков. «ЛОВЕЦ СНОВ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анастасия Веденская, Сергей Губанов, Сергей Рудзевич, Виолетта Давыдовская, Любовь Германова. «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.45 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20 «Кто кого?» 12+
06.30 «Всё о главном» 12+
07.00, 12.50, 14.50, 22.25 Новости
07.05, 21.40, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.30, 12.30 Специальный репортаж 12+
09.50 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Япония – Испания. Прямая трансляция из Новой Зеландии
12.00 «Спортивный век» 12+
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
15.50 «Громко». Прямой эфир
16.55 Футбол. МЕЛБЕТ-Первая Лига. «Алания» (Владикавказ) – «КАМАЗ» (Набережные Челны). Прямая трансляция
19.00 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. «Спартак» (Москва) – «Балтика» (Калининградская область). Прямая трансляция
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Турнир «Легендарный Севастополь». Прямая трансляция из Москвы
00.45 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Обзор 0+
01.15 «Вы это видели» 12+
01.55 Футбол. Чемпионат Бразилии. «Гояс» – «Гремио». Прямая трансляция
04.00 Пляжный волейбол. Чемпионат России. Мужчины. Финал. Трансляция из Санкт-Петербурга 0+

НТВ

05.00 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Детектив «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.20 «Основано на реальных событиях». «ЯД ДЛЯ БАНКИРА» 16+
01.15 Детективный сериал «ДИКИЙ» (S) 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить». Выигрыш 16+
12.25 «Порча». Материнские чувства 16+
12.55 «Знахарка». Мышь серая 16+
13.30 «Верну любимого». Призрак 16+
14.05 «Голоса ушедших душ». Божья коровка 16+
14.40 «ГРУЗ ПРОШЛОГО» 16+
19.00 «БЛОНДИНКА И БРЮНЕТКА» 16+
23.20 «Понять. Простить». Выигрыш 16+
00.35 «Порча». Материнские чувства 16+
01.00 «Знахарка». Мышь серая 16+
01.25 «Верну любимого». Призрак 16+
01.55 «Голоса ушедших душ». Божья коровка 16+
02.20 «ТРОЕ В ЛАБИРИНТЕ» 16+
04.10 «Преступления страсти». Прощай, ад! 16+

ЗВЕЗДА

06.15 «Сибирский характер против Вермахта». Документальный фильм. 16+
07.40, 09.15 «ПРИКЛЮЧЕНИЯ ШЕРЛОКА ХОЛМСА И ДОКТОРА ВАТСОНА». «СОКРОВИЩА АГРЫ» 12+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
11.05, 13.25 «ЦЫГАНКИ». Телесериал. 1-я – 6-я серии 16+
18.10 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Города-крепости» 16+
19.55 «Загадки века с Сергеем Медведевым». Документальный сериал 12+
23.15 «СЛУШАТЬ В ОТСЕКАХ» 12+
01.45 «В НЕБЕ «НОЧНЫЕ ВЕДЬМЫ» 12+
03.05 «ПОДВИГ РАЗВЕДЧИКА» 12+
04.35 «Перелом. Хроника Победы». Документальный сериал 16+

1 август | Сишәмбе

ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 16+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 16+
08.10 Утренняя программа «Здравствуйте!» 16+
09.00, 17.00 «КИТӘМ, ДИМӘ». Телесериал 16+
10.00, 23.00 «УЧИТЕЛЯ». Телесериал 16+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 16+
11.15 «Память сердца» 16+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 22.00 «ЧЕМПИОННАР ӘНИЛӘРЕ». Телесериал 16+
13.00 «Родная земля» 12+
13.30 «Юлчы» 16+
14.00 «Путь» 16+
14.15 «Не от мира сего…» 16+
14.45 «Музыкаль мәйдан» 16+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә». «Төймә» 0+
16.00, 21.00 «Ватандашлар» 16+
18.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 16+
19.00 «Таяну ноктасы» 16+
20.00 «Туган авылым» 12+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 16+
00.00 «Видеоспорт» 16+
00.25 «Каравай». Лоскутное шитье 6+
00.50 «Соотечественники». Фаяз Хузин. Путешественник во времени 16+
01.15 «КВН РТ-2022» 16+
02.05 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 16+
03.30 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
03.55 «Аулак өй» 6+
04.45 «Точка опоры» 16+
05.35 «Оныта алмыйм…» Ретро-концерт 12+

ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.05, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 16+
08.00 «Уткәннәр сагындыра» 12+
08.40, 18.20, 23.10, 04.20 «Җырлыйк әле!» 12+
09.40 «Халык җырлары» 6+
10.30 «Заман көзгесе» 6+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 16+
11.30 «Нәсыйхәт» 16+
12.05, 21.25 «Ком сәгате» 16+
15.30, 03.05 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 6+
16.00 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
16.30, 20.30, 02.40 «Таяну ноктасы» 16+
17.00 «Музыкаль мәйдан» 16+
17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
19.10, 22.15 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 12+
20.00 «Халкым минем» 12+
00.15 «Тамчы-шоу» 6+
03.30 «Йөрәктән – йөрәккә». Әнвәр Гобәйдуллин турында телеочерк (субтитрлы) 16+
01.10 «Әй, язмыш, язмыш…» 16+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости (с субтитрами)
09.20 «АнтиФейк» 16+
10.00 «Жить здорово!» 16+
10.50 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
16.00 «Мужское/Женское» 16+
16.50 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.30 Информационный канал 16+
19.55 «Куклы наследника Тутти» 16+
21.00 «Время»
22.00 «КАЗАНОВА». Многосерийный фильм (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 «АнтиФейк» 16+
00.40 ПОДКАСТ.ЛАБ «Легкие деньги» 16+
01.20 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+
01.55 ПОДКАСТ.ЛАБ «Повара на колесах» 16+
02.30 ПОДКАСТ.ЛАБ «Неформат» 16+
03.00 Новости
03.05 ПОДКАСТ.ЛАБ «Письма» 16+
03.50 ПОДКАСТ.ЛАБ «Свидетели Эйзенштейна» 16+
04.25 ПОДКАСТ.ЛАБ «20 лет спустя» 16+

РОССИЯ 1

05.00 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.30 «Утро России»
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 16.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 Сергей Безруков, Светлана Ходченкова, Андрей Мерзликин, Анна Михалкова, Сергей Маковецкий, Ирина Пегова, Виктор Сухоруков. «ГОДУНОВ» 16+
16.30 «Малахов» 16+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Пётр Рыков, Мария Андреева, Ольга Кабо, Полина Филоненко, Юрий Ицков. «ЛОВЕЦ СНОВ» 12+
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым» 12+
02.05 Анастасия Веденская, Сергей Губанов, Сергей Рудзевич, Виолетта Давыдовская, Любовь Германова. «РАЯ ЗНАЕТ ВСЁ!» 12+
03.45 Ярослав Бойко, Анатолий Васильев, Раиса Рязанова, Дарья Повереннова, Илья Соколовский. «СЕМЕЙНЫЙ ДЕТЕКТИВ» 16+

МАТЧ ТВ

06.00, 14.20 «Кто кого?» 12+
06.30 «Наши иностранцы» 12+
07.00, 12.50, 14.50, 18.30, 22.25 Новости
07.05, 15.25, 18.35, 21.30, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
09.30, 12.30 Специальный репортаж 12+
09.50 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Португалия – США. Прямая трансляция из Новой Зеландии
12.00 «Спортивный век» 12+
12.55 «Есть тема!» Прямой эфир
14.55 «География спорта. Белоруссия» 12+
16.15 Смешанные единоборства. UFC. Дастин Порье против Джастина Гейджи. Трансляция из США 16+
17.30 Футбол. МИР Российская Премьер-Лига. Обзор тура 0+
19.15 Футбол. FONBET Кубок России. «Амкал» (Москва) – «Знамя» (Ногинск). Прямая трансляция.
22.30 Дартс. Профессиональная лига. Турнир «Легендарный Севастополь». Прямая трансляция из Москвы
00.45 Футбол. Чемпионат мира. Женщины. Обзор 0+
01.15 «Шинная борьба». Документальный сериал. 1-я и 2-я серии 16+
03.10 Новости 0+
03.15 Триатлон. Мировая серия. Мужчины. Трансляция из Великобритании 0+
04.30 Гольф. Чемпионат Московской области 0+

НТВ

04.55 Сериал «УЛИЦЫ РАЗБИТЫХ ФОНАРЕЙ» 12+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.35 «Сегодня»
08.25, 10.35 Сериал «ЛЕСНИК» (S) 16+
13.25 «Чрезвычайное происшествие»
14.00 Сериал «СКОРАЯ ПОМОЩЬ» (S) 16+
16.45 Премьера. Сериал «ЗИМОРОДОК» (Турция) (S) 16+
20.00, 00.00 Детектив «МЕНТОВСКИЕ ВОЙНЫ» (S) 16+
00.20 «Основано на реальных событиях». «ЯД ДЛЯ БАНКИРА» 16+
01.05 Детективный сериал «ДИКИЙ» (S) 16+
04.05 «Герои «Ментовских войн» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
07.55 «Давай разведёмся!» 16+
08.55 «Тест на отцовство» 16+
11.10 «Понять. Простить». Побег 16+
12.25 «Порча». Красные слезы 16+
12.55 «Знахарка». Ноша 16+
13.30 «Верну любимого». Крепкая семья 16+
14.05 «Голоса ушедших душ». Шалопай 16+
14.40 «ЖЕНИТЬ НЕЛЬЗЯ РАССОРИТЬ» 16+
19.00 «ИДУ ЗА ТОБОЙ» 16+
23.15 «Понять. Простить». Побег 16+
00.25 «Порча». Красные слезы 16+
00.55 «Знахарка». Ноша 16+
01.20 «Верну любимого». Крепкая семья 16+
01.50 «Голоса ушедших душ». Шалопай 16+
02.15 «ДОЛГОЖДАННАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
03.50 «6 кадров» 16+

ЗВЕЗДА

05.00 «БЕЗ ПРАВИЛ». Телесериал. 1-я – 4-я серии 16+
09.00, 13.00, 19.00 Новости дня 16+
09.15 «ГОЛУБЫЕ МОЛНИИ» 12+
11.05, 13.25 «ЦЫГАНКИ». Телесериал. 7-я – 12-я серии 16+
18.10 «Неизвестные сражения Великой Отечественной». Документальный сериал. «Калинин» 16+
19.55 «Улика из прошлого» 16+
23.15 «РИСК – БЛАГОРОДНОЕ ДЕЛО» 12+
00.55 «ДАЧНАЯ ПОЕЗДКА СЕРЖАНТА ЦЫБУЛИ» 12+
02.10 «Нюрнберг». Документальный сериал 16+
04.15 «Суперкрепость по-русски». Документальный фильм 12+

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ УКАЗЫ

2023 елның 1 августыннан 2024 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын аулау лимитын раслау турында

«Ау турында һәм аучылык ресурсларын саклау хакында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы Федераль законның 24 статьясы нигезендә, Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгының «Аучылык ресурсларын аулау лимитын килештерү турында» 2023 елның 7 июлендәге 05-29-29/24680 номерлы хатын һәм Татарстан Республикасы Экология һәм табигать ресурслары министрлыгының 2023 елның 8 июнендәге 711-п номерлы боерыгын исәпкә алып, **карар бирәм:**

1. 2023 елның 1 августыннан 2024 елның 1 августына кадәрге чорга Татарстан Республикасы территориясендә аучылык ресурсларын аулау лимитын 1 нче кушымта нигезендә расларга.

2. Әлеге Указның 1 пункты белән расланган аучылык ресурсларын аулау лимиты чикләрендә һәр аучылык биләмәсе өчен аучылык ресурсларын аулау квоталарын 2–9 нчы кушымталар нигезендә билгеләргә.

3. Татарстан Республикасының Биологик ресурслар буенча дәүләт комитеты рәисенә Указның үтәлешен контрольдә тотуны тәэмин итәргә, шулай ук аның күчермәсен Россия Федерациясе Табигать ресурслары һәм экология министрлыгына билгеләнгән вакытларда тапшырырга.

4. Әлеге Указ рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе
Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль. 2023 ел, 26 июль. № 510

Әлеге Указ барлык кушымталары белән PRAVO.TATARSTAN.RU адресында Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырылган.

Август аена халык сынамышлары

vk.com

✓ Августның беренче атнасында тотрыклы һава торышы сакланса, кыш озын һәм карлы булыр.
✓ Август яңгырсыз килсә – җылы һәм коры көзгә.
✓ Августта бәс төшсә, иртә кышка ишарә.
✓ Августта берничә тапкыр яшен булса, көз озак булыр.
✓ Җылы, яңгырлы август – гөмбә уңышына.
✓ Августта торналар төркем-төркем булып җылы якка китсә, кыш иртә килер.
✓ 1 августта яңгыр яуса, көз елак, коры булса – көз дә шундый.
✓ 2 августта коры булса, алты атна буе шундый һава торышы сакланыр. Әгәр яңгыр яуса, алты атна тоташ яңгыр явар.
✓ 3 августта көне буе яшенле яңгыр яуса, боз да көтегез.
✓ 4 августта кичке томан җир өстенә җәелсә, эссе көннәр киләчәк.
✓ 5 августта күктә каурыйсыман болытлар күренсә, көннәр суыта.

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ТИМЕРСЕЗ БУЛМЫЙ

Күпме генә йокласаң да, йокы туймый, чәч коела, көн дәвамында хәлсезлек сизелә... Гемоглобины түбән булган кешеләргә таныш билгеләр бу. Җир шарында яшәүче һәр өч кешенең берсе кандагы гемоглобинның түбән булуыннан интегә, ди белгечләр. Аны ничек күтәрергә? Гемоглобинның югары булуы нәрсәсе белән куркыныч?

Әлеге сорауларга доцент, медицина фәннәре кандидаты, терапевт Регина АХУНОВА ачыклык кертте.

:: Гемоглобин ни сәбәпле түбәнәя? Түбәнәю нәрсәсе белән куркыныч?

– Гемоглобины түбән булган кеше вируслы инфекцияләргә ешрак бирешә. Кандагы эритроцитлар күләме кими, гемоглобин түбәнәя, йөрәк көчәнеп эшли, организмга кислород җитми башлый. Гемоглобин түбәнәюне икенче төрле анемия дип атыйлар. Ул организмдагы бик күп хилафлыклар (ризыкның начар үзләштерелүе, эчке кан китү, шеш, инфекция) турында кисәтә ала. Түбән калорияле диета яки вегетарианлык белән мавыккан, даими рәвештә донор буларак кан тапшырган, яңа гына операция ясаткан кешенең гемоглобины түбән булырга мөмкин. Хатын-кызларның күрем вакытында да җиңелчә анемия күзәтелә ала.

:: Гемоглобинның нормадан югары булуы куркынычмы?

– Гемоглобинның нормадан югары булуы йөрәк, үпкә эшчәнлегенең җитмәлекле булмавы, эритремия, бөер авырулары турында кисәтә. Кандагы гемоглобин күләменең чамадан тыш артып китүенә озак вакыт авыр физик эш башкару, стресс, билгеле бер дарулар эчү, таулы районнарда яшәү дә сәбәпче булырга мөмкин. Күп еллар дәвамында тәмәке тарткан, пычрак һавалы зур шәһәрләрдә яшәүчеләр дә гемоглобины югары булудан интегә. Шул рәвешле гемоглобинның түбән булуы да, югарылыгы да бик күп җитди авырулар турында кисәтергә мөмкин. Шуңа күрә организмда беренче билгеләр сизелүгә үк табибка мөрәҗәгать итәргә кирәк. Үзлегеңнән генә дәваланырга маташу – зур хата.

Гемоглобин нормасы

Яшь, җенес		Норма (г/л)
Ир-атлар		130–160
Хатын-кызлар		115–145
Балалар	тугач та беренче өч көндә	145–225
	җиде көнлек бала	135–215
	ике атнага кадәр	125–205
	1 айда	110–175
	2 айда	90–140
	3–6 айда	90–135
	1–6 яшь	110-140
	7–12 яшь	110–145
	13–15 яшь	115 – 150

:: Билгеләр дигәннән, гемоглобинның түбән яки югары булуын нинди билгеләр буенча чамалап була?

– Гемоглобинның нормадан югары булуының ниндидер үзгә билгеләре юк диярлек. Ә менә ул түбән булганда кеше тиз арый, хәлсезлек сизә, баш авыртудан тилмерә, йокысы бозыла. Әйткәнемчә, гемоглобин канга, бигрәк тә тукымаларга кислород җитмәү аркасында түбәнәя. Шуңа күрә анемия вакытында иң беренче чиратта тән тиресе агара, хәлсезлек сизелә, кеше тиз арый, башы әйләнә, тыны кысыла. Кандагы гемоглобин дәрәҗәсе гомуми кан анализы ярдәмендә ачыклана.

vk.com

Гемоглобин нормада булсын өчен киңәшләр

✓ Иң элек елына ким дигәндә бер тапкыр булса да гомуми кан анализы тапшырырга кирәк. Болай эшләгәндә, гемоглобин күләмендәге беренче үзгәрешләрне башлангыч чорда ук күреп алырга мөмкин. Анализ нәтиҗәләрендә үзгәрешләр булса, кичекмәстән табибка күренергә кирәк.

✓ Туклану, яшәү рәвешен фәкать белгеч белән киңәшләшеп кенә үзгәртү хәерле.

✓ Тәмәке – гемоглобинның дошманы. Сөрем газы гемоглобинның күзәнәкләргә кислород тапшыру сәләтен киметә. Шуңа күрә бу начар гадәттән баш тарту хәерле.

✓ Туклануга да зур игътибар бирергә кирәк. Анемияне кисәтү өчен аксымга бай ризыклар, составында тимер булган ярмалар, яшелчә, җиләк-җимеш ашарга киңәш ителә. Гемоглобины югары булган кешегә исә диңгез ризыкларына, ак ит, чикләвек, кузаклыларга өстенлек бирергә кирәк.

:: Анемия вакытында ничек тукланырга?

– Гемоглобин түбән булганда, бавыр, ит, карабодай, хәлвә, чөгендер, гранат, кишер, кипкән җиләк-җимеш, чикләвек, уылдык, бал, кычыткан, йомырка, балык, шоколад, гөлҗимеш, кара карлыганга өстенлек бирергә кирәк. Ә менә банан, лимон, виноград, соя, ясмык, төче су балыгы, яшелчәләр, солы, арпа ярмасы, сыр, эремчек кебек ризыклар аны, киресенчә, төшерә.

Абау!

Су өянәктән коткара

Җитәрлек күләмдә су эчмәгән кешегә баш өянәге куркынычы яный. Неврологлар шулай дип кисәтә. «Әгәр кеше суны аз эчә икән, кан начаррак йөри башлый, баш мие тиешенчә тукландырылмый. Шуңа күрә өлкән кеше көненә ким дигәндә 2–2,5 литр чиста су эчәргә тиеш», – ди белгечләр.

Тмин шифалы

Төркия галимнәре тмин маеның шикәр чирен булдырмый калырга ярдәм итүен ачыклаган. Моннан тыш ул газлар җыелуны булдырмый, нервларны тынычландыра, иммунитетны ныгыта икән.

Чама кирәк

Галимнәр шашлык белән мавыкмаска киңәш итә. Баксаң, учакта кыздырылган иттә бензопирен канцерогены туплана икән. «Шашлыкны сирәк ашаганда организм бу зарарлы матдәне чыгарып бара, ә еш куллану организмны, киресенчә, агулый», – ди белгечләр.

Исеңдә тот!

Варикозны кисәтү өчен

1 Иртән уянгач, урыныгыздан кисәк кенә торып китмәгез.

2 Яткан килеш кенә киерелеп-сузылып алыгыз. Аяк-кулларыгызны сузып торыгыз.

3 Аннан аяк-кулларыгызны гәүдәгезгә перпендикуляр рәвештә күтәреп, табаныгызны үзегезгә карата тып сузыгыз. 3 минут дәвамында вибрация ясап, селкетеп торыгыз.

Әлеге гади күнегүләр кан тамырларына холестерин, тозлар утырудан саклый. Бөтен организм буйлап кан әйләнешен яхшырта. Бу ысул кул-аякларыны оеп интегүчеләргә аеруча файдалы булачак.

Киңәш-табыш

Тамак авыртса

Ярты литр кайнар суга 3–4 яшь кура җиләге яфрагын ботагы белән бергә салып, 10–15 минут төнәтергә кирәк. Лимон телеме белән бал да өстәргә була. Шуны эчүнең файдасы зур. Кура җиләге яфрагын кышка киптереп куярга да онытмагыз. Балаларга да бирергә була.

Укучы хаты

ГЫРЛАУДАН КОТЫЛДЫМ

Йоклаганда гырлый торган гадәтем бар. Өйдәгеләр гел шуннан зарлана. «Ромашка төнәтмәсе гырлаудан ярдәм итә», – дип укыган идем. Дөрестән дә, файдасы бар икән. Аны куллануның бер авырлыгы да юк. Ромашка төнәтмәсе ясыйсың да йоклар алдыннан шуның белән тамак чайкыйсың.

РАВИЛ абыегыз. Азнакай

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

КӘБЕСТӘ НИГӘ ЯРЫЛА?

Вакытында утыртып, тәрбияләп, суын да сиптем, тик кәбестәләр ярыла, дип зарлана күп кенә бакчачылар. Моның сәбәбе нидә? Аны саклап калып буламы? Һәвәскәр бакчачы Гөлфия ХӘНИПОВА әлеге сорауларга җавап табарга ярдәм итте.

Суны дөрес сип!

Кәбестәнең ярылуы күпчелек очракта аңа дөрес су сипмәүгә һәм вакытында җыеп алмауга бәйле. Әлеге әйтеп үтелгәннәрдән тыш тагын башка сәбәпләре дә бар, әлбәттә.

Кәбестәгә тигез итеп су сипмәү аны харап итә. Өстеннән су койдың да шул җитте генә түгел. Тамырына суны артыграк сибү дә ярамый. Сирәк сипкәндә, кәбестәнең яфраклары «биргәндә алып калыйм әле» дигәндәй, суны күбрәк йотарга тырыша. Шунлыктан кәбестә тизрәк үсә башлый. Кәбестә яфраклары тизрәк үсә башлаганлыктан, аның башы мондый кискен үсешкә түзеп тора алмыйча, ярыла. Шунлыктан монда чама хисе турында онытырга ярамый. Иң яхшысы – кәбестәгә суны 1 кв. метрга 10–12 литр исәбеннән сибү. Әлбәттә, салкынча көннәрдә атнага бер дә җитә, ә эсседә суны атнага 2 тапкыр сибәргә кирәк. Шунысына игътибар итегез: кәбестә үскән туфрактагы дым 20–25 сантиметрга кадәр төшкән булса яхшы. Суны көндез түгел, ә иртән яки кич сибү файдалырак.

Артыгы файдасыз

Температураның кискен үзгәрешләре, озакка сузылган яңгырлар, корылык шулай ук кәбестә ярылуга сәбәпче була. Яңгырлар озакка сузылса, кәбестәгә тагын да ныграк зарар килмәсен өчен, аны пленка белән каплап торырга мөмкин. Аның кайчан өлгерешле булуына да игътибар итегез. Иртә өлгерә торган кәбестәләргә суны – июньдә, ә соң өлгерә торганнарга августка даими сибәргә кирәк. Бу нык, сусыл кәбестә формалашуга ярдәм итә.

Соңга калма!

Кәбестәне кайчан һәм ничек җыеп алу да мөһим. Өлгергән кәбестә тагын да дым алуын дәвам итә икән, ярылмый нишләсен инде?! Иртә өлгерә торган кәбестәне, көзен җыелыр әле, дип тотудан файда юк. Орлык сатып алганда кәбестәнең рәсеменә генә түгел, аның кайчан өлгерүенә дә игътибар итегез. Иртә өлгерешлене – июнь ахырыннан башлап, уртача өлгерешлене – августта, ә соң өлгерешле кәбестәне сентябрьдә җыярга киңәш ителә.

Ярылган кәбестәләрне ташларга ашыкмагыз. Чистартып, суга салып тотканнан соң алар хәзер ашау өчен яки кышка салатлар ясау, яшелчә ашлары пешерү өчен менә дигән!

vk.com

Корткычлардан коткарабыз

✓ 10 л суга 3 аш кашыгы сода, 2 аш кашыгы үсемлек мае һәм 2 аш кашыгы дегетле сыек сабын салып болгатырга. Иң мөһиме: соданы салганчы башта кайнап чыккан суга салып «чыжылдатырга» кирәк. Әлеге «дару»ны кичке якта кәбестәләргә сиптереп чыгарга. Атна дәвамында 2–3 тапкыр сиптергәннән соң файдасын күрерсез.
✓ 3 литр суга бер шешә валерианка, бер аш кашыгы сыек сабын салып болгатырга. Әзер төнәтмәне корткычлар зарарлаган кәбестәгә сибәргә. Уңыш җыярга бер ай калгач кәбестәне нашатырь спирты белән эшкәртергә була. Моның өчен бер шешә (40 г) нашатырь спиртын 5 литр суга салып, ике кашык сыек сабын өстәп сибәргә кирәк.

Укучы киңәше

АЛ ДА ОНЫТ...

Узган ел утырткан сарымсагым әле хәзер дә үрмәдә һәм бозылмады да! Ничек сакладың соң, дисезме? Дөресен әйткәндә, мин аны алдым да оныттым... Җыеп алганнан соң, тамырын һәм сабакларын өзми генә бәйләп, яхшы җилләтелә торган утын сараена элеп куйдым. Ул кара көзгә кадәр шунда эленеп торды. Салкыннар башланыр алдыннан тамырына тимичә, сабагын 20–25 см чамасы калдырып кисеп, өйгә керттем. Кәгазь тартмаларга салып, караңгы урынга куйдым. Берни эшләмәгән сарымсакларымны ташларга кызганыч.

Туксанны узган әнием мондый киңәш бирде: «Ташлама, көзгә утырт син аны, кызым, үсә ул», – ди. Эксперимент уңышлы булса, сезгә дә язармын, яме.

Зөлфия ДӘҮЛӘТШИНА. Мамадыш

БОРЫЧ УҢЫШЫН АРТТЫРА

Башта түтәлгә су сибәбез. Аннары 10 л суга 2 аш кашыгы кальций селитрасы салып, лейка белән сибәбез. Катнашма баклажан һәм помидор уңышын арттыру өчен дә әйбәт. Шулай ук черек авыруыннан профилактика чарасы буларак та кулланыла.

Үзем сынадым

Роза үрчетер чак

Бакчачы журналист Роза Нургалиева үрмәле розаны үрчетү буенча киңәшен бирде.

– Розалар үрчетергә өйрәнеп киләм. Үрмәләп үсүче, куаклы розаларны үрчетү иң җайлысы, чөнки алар гәлҗимешкә ялгап чыгарылмый, алар, русча әйтсәк, «корнесобственные», беркайчан кыргыйланмыйлар, чыбыкчадан үрчетә аласыз.

«Фламментанц»ны крыжовник кебек ботагын җиргә бөгеп күмдереп куюда да җитә. Узган елгы сынаулар уңышлы узды – быел өч зур үсенте алдым. Хәзер тагын куячакмын. Хәзер моның өчен иң яхшы вакыт. Чираттагы тәҗрибә – Канада розасы белән. «Джон кэбот» сортлы Канада розасының (фотода) ике ботагы «Корневин» өстәлгән суда 3 атнада тамыр җибәрде. Әлегә кечерәк чүлмәккә утырттым, сентябрьдә җиргә күчерәчәкмен. Канада розалары 35 градуслы салкыннарга да чыдам, әмма яшь үсентене тиешенчә каплап калдырырга кирәк.

Кышка әзерлек

ЧИЯ КАЙНАТМАСЫ

Замирә РӘҖӘПОВА рецепты

11 стакан чиягә ярты стакан чамасы су салып, 10 минут кайнаттым. Артыгы кирәкми! Аннары шуңа 7 стакан шикәр комы салып, тагын 10 минут кайнаттым.

Уттан алып, тагын 7 стакан шикәр комы салып, эреп беткәнче болгаттым. Утка куеп, кайнатып чыгардым һәм сүндердем. Стерильләштерелгән банкаларга тутырып куйдым. Бик тәмле һәм бик ансат эшләнә. Чияләре катып китми, йомшак килеш кала.

КАРАҖИМЕШ + ЧИЯ

Эльвира Вәлиева рецепты

Кирәк: *3 кг төше алынган чия, 600 г караҗимеш, 3600 г шикәр комы (1 килограммга 1200 г исәбеннән).*

Юып чистартылган, төше алынган чиягә 4 өлешкә бүленгән караҗимешләрне һәм шикәр комын салып, сүрән утта кайнатып чыгарырга. Күбекләрен алып, бертуктаусыз болгата-болгата 15 минут кайнатырга. Стерильләштерелгән банкаларга кайнар килеш тутырырга.

Тәмле булсын!

Яраттыра торган борщ

«Борщ яратам, тик пешерергә яратмыйм», – диючеләргә киңәш

Чынлыкта аны пешерүнең бер кыенлыгы да юк. Әзер ит шулпасында туралган кәбестә, кишер, суган, бәрәңге пешә тора, ә без чөгендерне аерым табада пешереп алабыз.

Менә болай эшләгәндә чөгендернең кызылы чыгып бетми, борщның төсе матур була.

Ике уртача зурлыктагы чөгендерне (вак булса, өчне) эре угычтан уабыз. Майлы табага салабыз. Аңа 2 аш кашыгы шикәр комы, 1 яки 1,5 аш кашыгы серкә салып болгаткач, капкачын каплап, пешерергә куябыз. 20–25 минуттан чөгендер әзер!

Аны ашка салабыз. Вакланган 2 тырнак сарымсак өстибез. Сүрән утта кайнатып чыгарабыз да 1–2 минуттан сүндерәбез. Артыгын кайнатасы түгел! Алайса төсенең матурлыгы калмаячак.

Гөлнара ЗИННӘТУЛЛИНА әзерләде

ИСЕМЕҢ МАТУР, КЕМНӘР КУЙГАН?

Көтеп алган сабыеңа яңгырашлы, мәгънәле исем кушасы килә. Исеме генә түгел, тормышы да, язмышы да матур булсын! Бар яктан ярашлы, җисеменә туры килгән исемне ничек сайларга?

«Туган авылым» мәчете имам-хатыйбы Нурулла хәзрәт ЗИННӘТУЛЛИН белән шул хакта сөйләштек.

:: Нурулла хәзрәт, яңа туган сабыйга исемне ничә көн эчендә кушарга кирәк?

– Балага җиде көнгә кадәр исем бирелергә тиеш. Мулла чакырып, азан әйттереп исем кушуны соңрак та башкарырга мөмкин. Әмма ата-ана аңарчы балага исем бирергә тиеш. Яңа туган баланы исемсез тотарга ярамый.

:: Кайберәүләр тормышындагы борчу-хәсрәт, чир һәм уңышсызлыкларны исеменнән күрә. Кешенең исеме аның язмышына йогынты ясыймы?

– Халык уйлап чыгарган ырым-шырым гына түгел бу. Динебездә әйтелгән сүзләр. Пәйгамбәребез Мөхәммәд Мостафа салләллаһу галәйһи вә сәлләм начар мәгънәле исемнәрне алыштыра торган булган. Ул моны: «Исем җисемгә туры килә», – дип аңлаткан. Кешене яхшы исем белән атасаң – яхшылык, начар исем белән атасаң, начарлык тартып торырга мөмкин. Шуңа күрә бу сүзләрдә дөреслек бар. Кеше тормышта ниндидер авырлык кичерсә, авырып китсә, исемен үзгәртә ала. Андый чакта кешегә шулай эшләргә киңәш итәбез.

:: Сезгә исем алыштыруны сорап, еш мөрәҗәгать итәләрме? Күпчелек моны ни сәбәпле эшли?

– Андый гозер белән еш мөрәҗәгать итәләр. Күпләр кемнеңдер киңәшенә колак салып бу адымга бара. Кешегә начар мәгънәле исем кушылган булса да, исемен үзгәртергә кушабыз. Исемен ошатмаганга күрә алыштыручылар да бар. Андыйларга да каршы килмибез. Дингә килгән кеше дә еш кына исемен алыштыра.

:: «Нар»га тәмамланган исемнәр кешегә бәхетсезлек китерә дигән фикерне еш ишетергә туры килә. Ниндидер иҗек аркасында гына исемгә шикләнеп карау дөресме?

– «Нар» – ут дигән сүз. Ут бит инде ул тәмуг, пешерү, яндыруга бәйле. Шуңа күрә андый исемнәрне алыштыру хәерле. Әмма, мисал өчен, Гөлнар дигән исем – искәрмә. Ул «ут чәчәге» дигәнне аңлата. Шуңа күрә бу исемне алыштырмасаң да була. Һәр очрак – индивидуаль. Кешенең тормышында авырлыклар килеп чыгып, исемен алыштырырга карар итә икән, бу – аның ихтыяры. Тормышында бар да тәртиптә булса, «нар»га тәмамланган исем йөртүнең дә куркынычы юк.

:: Дин буенча тагын нинди исемнәрне кушарга киңәш ителми?

– Дини яктан караганда, башка дингә бәйле исемнәрне кушу тыела. Моңа Марс, Венера, Диана кебек исемнәр керә. Болар – мәҗүси исемнәр. Аларны кушкач, син дә шул дингә караган булып чыгасың. Мәгънәсе ямьсез булган исемнәр дә бар. Андыйлар совет чорында күп очрый иде.

:: Исем ошамаганда, мулла сабыйга исем кушудан баш тарта аламы?

– Мулла кушмаса да, ата-ана балага исем биргән була. Өстәвенә хәзер сабыйлар бала тудыру йортыннан ук исемле булып чыга. Ник дигәндә, шунсыз документ ясатып булмый, ә ансыз чыгармыйлар. Шуңа күрә бу очракта мулланың фикер, киңәше күләгәдә кала. Күз алдына китерик. Мулла балага исем кушарга килде, ди. Исемне ошатмыйча, аны кушудан баш тарта. Сабыйның ата-анасы белән киңәшләшеп, икенче исем сайлыйлар да, мулла шуны кушып, тыныч күңел белән китеп бара. Тик бу баланы әлеге исем белән йөртмәячәкләр бит. Барыбер документтагы исеме калачак. Шуңа күрә кайчак исем кушу йоласы шулай икейөзлелек, фарс кебек килеп чыга.

:: Якын кешесенең истәлеге булсын дип, балага үлгән кеше исемен кушучылар да бар.

– Соңгы елларда ретро форма сатып алучылар артты. Элекке мода кире кайта бит. Күбрәк авыллардан киләләр. Күлмәк, ак алъяпкыч – 2 мең сум. Кыргызлар теккәненең хакы шундый. Безнекеләрнеке кыйммәт, – ди сатучы, – Һәр елны бер үк төрле әйберләр сорыйлар. Сарафаны, җилеты, чалбары – барысы да кирәк. Бер баланы укырга әзерләү өчен 25 мең сумсыз да булмый. Хәзер портфельнең яхшысы үзе генә дә 5–6 мең сум тора бит.

Портфельләрнең бәяләре 800дән 8 мең сумга кадәр тирбәлә. Ортопедик дигәне кыйммәт. Әти-әниләр, балаларның сәламәтлеген күздә тотып, шунысы алырга тырыша.

– Узган ел акчаны кызганып, кызыбызга букчаны 1 мең сумга сатып алган идек. Ярты елга да җитмәде, ертылды. Шуңа күрә быел 6 мең сумлыгын сайладык, – ди базарга кызын ияртеп килгән Диләрә Гайсина.

Портфель – 800–8000 сум
Дәфтәр – 5–30 сум
Дәфтәр тышы – 2–20 сум
Карандаш – 5–10 сум
Карандаш очлагыч – 6–25 сум
Бетергеч – 6 сум
Альбом – 18–120 сум
Пластилин – 99 сум
Пумала – 50–300 сум
Катыргы –78–199 сум
Акварель – 99–300 сум
Гуашь – 149 сум
Фломастер – 50–250 сум
Җилем –25–65 сум



Фикер

Фәнис ХӨСӘЕНОВ, Татарстан Иҗтимагый палатасының финанс һәм икътисад мәсьәләләре буенча белгече:
– Әти-әниләр шуны истә тотсын иде: уку кирәк-яракларын ярты ел алдан ук хәстәрләп куегыз. Кызганыч, бездә халыкның финанс белеме җитми. Шуңа күрә алар сезон җиткәч ала башлый. Бу шикәр комын җәен кайнатмалар кайнаткан чорда сатып алган кебек. Бала тиз үсә, шуңа күрә киемне бик иртә алып булмый анысы. Әмма дәфтәр, карандаш, портфель беркайчан да искерми. Җәй уртасыннан сентябрь башына кадәр бәяләр һәрвакыт уртача 10–30 процентка арта. Базар ул – бизнес. Сезон вакытында төп әйберләр кыйммәтләнә. Чөнки бөтенесе дә сатып ала. Шуңа күрә алдан алу ягын чамалагыз.

«Экономная мин»

Лаеш районында яшәүче өч бала әнисе Диләрә Сәгъдәтшина үзе турында шулай ди. Яңа уку елына балаларын күптән әзерләп куйган инде ул. Гадәте шундый икән. Хәзер вак-төяген хәстәрлисе генә калган. Зарифы әлегә бакчага йөри. Әмма анда мәктәптән ким әзерлисе түгел. Сатып аласы әйберләр исемлеге озын. Бертөрле булсын өчен, кирәкле әсбапларны әти-әниләр белән җыелышып алалар икән. Сәете – 8 нче сыйныфка, Азалиясе уку йортының икенче курсына җыена.

– Дәфтәр, дәфтәр тышлары, каләмне тартмасы белән алдан ук ел буена җитәрлек итеп алып куям. Ел буе запас туплыйм. Кайда нәрсә бар, шуны алам. Узган атнада Сәет белән «Детский мир»га барган идек. 4 мең сумлык костюм эленеп тора иде. Бераз зуррак булса да, үсә бит әле ул дип, сатып алдым. Узган елны базарда костюм 7 мең сум тора иде. Узган ел форманы елга ике тапкыр алдым. Ел башында һәм язга чыккач, улым үсеп китте чөнки. Формасы ярамый инде. Рюкзакны кыйммәтне алган идек, анысы ярый әле. Физкультура дәресенә кроссовка алдык. Башка аяк киемнәрен көз көне карарбыз әле. Сәеткә чәчәк букеты гына кирәк хәзер. Анысын әтием Камил үстерә. Зарифым киләсе елга мәктәпкә бара. Абыйсының киемнәре ярар дип уйлыйм. Букчага акча җәлләмәскә кирәк. Азалиягә арзанын алган идек, бик тиз ертылды, – ди Диләрә Сәгъдәтшина.

Буа районында яшәүче ике ул үстерүче Зөлфә Закирҗанова, әле мәктәп турында уйлаган да юк, өлгерербез, ди. Күпме акча киткәнне дә санарга яратмый ул.

– Мин уку кирәк-яракларын бер генә кибеттән алмыйм. Шуңа күрә арзанлысы да, кыйммәтлесе дә бар. Әлегә 2 нче сыйныфка бара торган улыбызга 1800 сумга чалбар алдык. Бәяләр арзан түгел. Калганына августта барырбыз, – ди ул.

Казанда яшәүче Миләүшә Вәлиеваның да ике улы бар. Олысы Инсаф – 8 нче, кечесе Искәндәр 5 нче сыйныфка бара. Ул да август җиткәнне көтә.

– Алдан сатып ала торган гадәтем юк. Дәфтәр, каләм кибеттә беркайчан да бетми бит. Бәясе дә әллә ни үзгәрми. Киемгә менә акча күп кирәк. Бер баланы әзерләү өчен кесәне ким дигәндә 15–20 мең сумга бушатырга туры киләчәк. Хәзер бит һәр мәктәпнең – үз формасы. Аның бәясе – 10 мең сум тирәсе. Моңа өстәп, аяк киеме, спорт формасы да кирәк. Шуннан чамалагыз инде, – ди Миләүшә.

Сәрия МИФТАХОВА

ИЛ КУШКАЧ

«ХӘРБИ БУРЫЧ ҺӘМ ХӘРБИ ХЕЗМӘТ ТУРЫНДА» ЗАКОНГА ТӨЗӘТМӘЛӘР КЕРДЕ

Россия Дәүләт Думасы хәрби хезмәт яшен арттыруга бәйле закон кабул итте. Шулай итеп, киләсе елдан армиягә 18 яшьтән 30 яшькә кадәрге ир-атлар чакырылачак. Моннан тыш армия хезмәтеннән качып йөрүчеләр өчен штраф суммасы да үзгәрде. «ВТ» белгечләр ярдәмендә әлеге үзгәрешләрне аңлата.

НИЧЕК ИДЕ, НИЧЕК БУЛЫР?

Россиядә армиягә чакыру яше ярты гасырдан артык үзгәрмәде. 1967 елдан бирле армиягә 18 яшьтән 27 яшькә кадәрге ир-атларны җибәрәләр иде. СССР таркалгач та шулай дәвам итте. Дәүләт Думасында «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законга кертелгән үзгәрешләр нигезендә, 2024 елның 1 гыйнварыннан Россиядә хәрби хезмәткә чакыру яше 18дән 30га кадәр озайтылачак.

ҮЗГӘРЕШЛӘР КЕМНӘРГӘ КАГЫЛА?

Закон нигезендә, 2023 елда 27 яшькә җиткәннәрне запаска алачаклар, ә быелгы көзге чакырылыш исә элеккечә узачак. Инде запаста булганнарга да закондагы үзгәрешләр кагылмаячак. Әгәр ир-ат хәрби билет алган һәм запастагы хәрби бурычлы статусына ия икән, ул чакырылышка кабат эләкмәячәк. Бу хакта Дәүләт Думасының Оборона комитеты җитәкчесе Андрей Картаполов та белдерде. «2023 елда 27 яшь тулган егетләр, 31 декабрьнең 23 сәгать 59 минутында 27 яшь тулса да, запастагы хәрби бурычлы саналачак һәм 2024 елда хәрби хезмәткә алынмаячак. Хәзер 28, 29 яше тулганнар инде запаста санала», – диде ул.

НИЧӘ ЕЛ ХЕЗМӘТ ИТӘЧӘКЛӘР?

Россия Кораллы Көчләрендә хәрби хезмәт вакыты – 12 ай, ягъни бер ел. Ул үзгәрешсез кала.

САН

147000

2023 елдагы язгы чакырылыш вакытында хәрби хезмәткә шулкадәр кеше чакырылды.

32360757

илдә 18 яшьтән 50 яшькә кадәрге ир-атлар саны (Росстатның былтыргы мәгълүматлары буенча)

27–30 ЯШЬ АРАЛЫГЫНДАГЫ ИР-АТЛАРГА НИШЛӘРГӘ?

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
27–30 яшьлек ир-атларга 27 яшькә кадәрге ир-атлар өчен булган бурычлар кагылачак. «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль законның 10 нчы статьясында андыйларның хәрби исәптә торырга тиешлеге әйтелә. Әгәр дә ир-ат 27 яше тулгач хәрби билет алган булса, әмма аңа әлегә 30 яшь тулмаган икән, ул үзгәреш кичергән яңа критерийларга туры килә, димәк, аны хәрби хезмәткә чакырулары ихтимал.

Артем Клыга, юрист:
Андыйлар «соры зона»да калырга мөмкин. Шуңа да 27 яше тулган егетләргә запаска чыгу һәм хәрби билет алу эшен бүгеннән үк кайгыртырга кирәк.

ПОВЕСТКА ТАПШЫРЫЛГАН ДИП САНАЛГАН ОЧРАКЛАР

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
«Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» Федераль закон нигезендә хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле гражданнар повестка алырга тиеш. Бу документ язма рәвештә җибәрелә һәм электрон рәвештә кабат җибәрелә (дубляж). Повестка хат тапшырылган көнне китерелгән дип исәпләнә.

Повестканы язма рәвештә расписка буенча алу дөрес санала. Повестка почта аша хат белән яшәү урыны адресы буенча тапшырыла яки хәрби комиссариат яисә оешма хезмәткәрләре тарафыннан эш (уку) урыны буенча шәхсән тапшырыла.

intertat.tatar

ХӘРБИ ХЕЗМӘТНЕ КИЧЕКТЕРЕП ТОРУ (отсрочка) КЕМНӘРГӘ КАРАЛГАН?

- ✓Югары уку йорты һәм аспирантурада укучы студентлар;
- ✓IT хезмәткәрләр;
- ✓ике һәм аннан да күбрәк балигъ булмаган балаларның әтиләре;
- ✓өч яшькә кадәр инвалид бала тәрбияләүчеләр;
- ✓ялгыз әтиләр;
- ✓йөклелекнең 26 нчы атнасында булган хатын-кыз белән рәсми никахта торучылар;
- ✓авыру туганнарын тәрбияләүчеләр;
- ✓олы яшьтәге ата-аналарын тәрбияләүчеләр.

Повестка электрон рәвештә гражданинга Дәүләт хезмәтләре порталы (Госуслуги) аша җибәрелә.

Әгәр дә повестка әлеге ысулларның берсен кулланып бирелгән булып саналмаса, ул повесткалар реестрында урнаштырылганнан соң 7 көн узгач тапшырылган дип исәпләнә.

ПОВЕСТКАНЫ БАШКА КЕШЕГӘ БИРҮ, ИШЕККӘ КЫСТЫРЫП КИТҮ КЕБЕК ОЧРАКЛАР

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
Югарыда әйтелгәннәрдән чыгып, гомуми кагыйдә буенча, повестка шәхсән тапшырыла. Повестканы ишеккә кыстырып китү дөрес түгел. Законда повесткаларны җибәрү ысуллары ачык күрсәтелгән: язма формада шәхсән һәм заказлы хат белән, эш бирүче аша, электрон формада Дәүләт хезмәтләре порталы һәм повесткалар реестры аша. Әгәр дә сез почтада яки эштә (укуда) кулыгызга хат алмасагыз да, повесткалар реестрында урнаштырылганнан соң 7 көн узгач, ул тапшырылган дип саналачак.

Фикер

Евгений КАБЫШ, Әфганстан ветераннары берлеге рәисе:
– Хәрби хезмәткә чакыруны 18 яшьтән калдыруны дөрес дип саныйм. Безнең чорда минем өчен иң кулае шулай иде. Хезмәт итеп кайтасың, укырга керәсең, армия этабы инде узылган. 21 яшьтә инде егетнең һөнәре була. Укып чыгып, эшләргә дә өлгереми, армиягә китәргә кирәк. Ул анда һөнәрен, аны нәрсәгә укыткаларын онытырга да мөмкин.

ПОВЕСТКАНЫ АЛГАЧ НИШЛӘРГӘ?

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
Хәрби комиссариатка килү бурычы куела. Нигезсез сәбәпләр белән килмәү качу дип саналачак, тискәре нәтиҗә бирәчәк.

НИНДИ ЧИРЛӘР АРМИЯДӘН АЛЫП КАЛА?

Булат Закиров, «ВТ» юристы:
Авыруларның тулы исемлеге Россия Хөкүмәтенең 04.07.2013 № 565 Карары белән расланган. Мәсәлән, начар күрү очрагында, ягъни 6 диоптрийдан артык ерактан начар күрү (близорукость), 8 диоптрийдан артык якыннан начар күрү (дальнозоркость), 4 диоптрийдан артык астигматизм белән ир-егетләр армиягә чакырылмаячак. Авырлык җитмәү яисә симерү дә бу исемлеккә керә. Шунысын да әйтергә кирәк: армия хезмәтенә чакырудан кичектерү бирә, әмма аннан азат итми торган авырулар исемлеге дә бар.

ВОЕНКОМАТКА БАРУДАН АЗАТ ИТӘ ТОРГАН СӘБӘПЛӘР

Хәрби хезмәткә чакырылучының авыруы яки аның якын туганнарының хәле авыр булу военкоматка килмәскә җитди сәбәп булырга мөмкин. Чакырылыш комиссиясе белән каралачак башка төр сәбәпләр дә моңа керә.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Нәрсә өчен штраф каралган?

(2023 елның 1 октябреннән гамәлгә керә)

ФИЗИК ЗАТЛАРГА	
10000–30000 сум	повестка буенча военкоматка килмәгән очракта (әлегә 500–3000 сум)
5000 сум	хәрби исәп-хисап өчен кирәк саналган мәгълүматларны яшергән өчен (гаилә хәле, яшәү урынын үзгәртү һ.б.) (әлегә 3000 сумга кадәр штраф)
5000–15000 сум	Россиядән ярты елдан артык вакытка китү турында хәрби комиссариатны кисәтмәгән очракта
10000–20000 сум	хәрби хезмәткә чакырылу чорында яшәү урыныннан 3 айдан артык вакытка киткән өчен
15000–25000 сум	медицина тикшерүеннән баш тарткан өчен (әлегә 3000 сумга кадәр штраф)
25000 сумга кадәр	аңлы рәвештә хәрби билетны бозган яисә юк иткән өчен (әлегә 3000 сумга кадәр штраф)

ВАЗЫЙФАИ ҺӘМ ЮРИДИК ЗАТЛАРГА	
40000–50000 сум 350000–400000 сум	хәрби комиссариатка хәрби учетта торырга тиешле кешеләр исемлеген бирмәгән очракта
60000–80000 сум 400000–500000 сум	мобилизация чорында «гражданнарның хәрби җыен пунктларына яки хәрби частьларга вакытында хәбәр итү һәм килүен тәэмин итү» буенча үз бурычларын үтәмәгән өчен

БАРЫСЫ ДА – БЕР ОЯДА

ГӨЛФИРӘ АСАДУЛЛИНА ТУГАННАРЫНЫҢ БАЛАЛАРЫН ҮЗЕНЕКЕЛӘРДӘЙ ТӘРБИЯЛИ

Асадуллиннарның гаилә архивыннан

«Кырык көн эчендә мин – сеңлем белән апамны, әни – ике кызын, ә биш сабый әниләрен югалтты...» Әлки районының Татар Мулласы авылында гомер кичерүче Гөлфирә Асадуллина тормышының асты өскә килгән көннәрен әле дә күз яшьләре белән искә ала. Алты балага гомер биргән Гөлфирә апа белән Рафис абыйга 11 бала – 8 кыз, 3 малай өчен тигез канат булырга туры килә бит...

Ишле, эшле һәм ашлы гаилә

...Кияүгә чыкканда Гөлфирә апага унҗиде дә тулмаган була әле. 30 елга якын иңгә иңне куеп яшәүче гаиләне авыр эш беркайчан да куркытмый.

– Өйләнешүгә, икебез дә фермада эшләдек. Ирем Рафис – механизатор, мин – сыер савучы. Аннан соң 11 ел буе авылдагы әби-бабайларны карадым. Ә 2009 елда, тәвәккәлләп, үз гаилә фермабызны булдырдык. Хәзерге вакытта 80ләп баш эре терлегебез бар. Гаиләбез ишле булгач ким дигәндә 100 үрдәк, 100 каз да асрыйбыз әле. Бер тотынсам, икешәр үрдәк пешерәм мин. Бер үрдәк белән кеше сугыштыралар димени? Аена бер үгез суябыз. Тормыш шулай бара инде, – дип санап китте хуҗабикә, шәһәр кешесен гаҗәпләндереп.

Җир җимертеп эшлиләр дә, бер-бер артлы алты балага тормыш та бүләк итә алар. «Барысы да туасы җаннар булган инде, Аллаһы Тәгалә шулай кушкандыр», – ди Гөлфирә апа.

Төзәлмәс яралар

...2017 елның кышкы буراннары Асадуллиннар гаиләсенә кайгы өстенә кайгы алып килә. Озак кына авырудан тилмергәннән соң, 33 яшен генә тутырган сеңлесен югалта Гөлфирә апа.

– Үземнән яшь сеңлемне югалту бигрәк авыр булды. Аның ире үлгән иде, балаларын – Айзилә белән Азалияне үзебезгә алып кайттык. Мин бит – ир хатыны, каенана белән яшәүче килен. Алар каршы килсә, алып та кайта алмас идем. Шөкер, якыннарым барысын да аңлады, – дип искә ала әңгәмәдәшем. – Ул чакта апамның да хәле җиңел түгел иде инде. Мәскәүгә – операциягә алып китәргә әзерләнеп йөргән көннәре... Сеңлемнең кырыгына кадәр апамны мунчага алып кереп чыктым әле. Кырыгы узуга, өч баласын калдырып, ул да китеп барды...

Бу хатирәләрне яңартканда, әңгәмәдәшемнең күзләре чыланган иде. Ничә ел узса да, төзәлерлек яралар түгел шул... Ул чакта 38 яшен генә тутырган Гөлфирә апага берөзлексез елаучы әнисен юатырга да, ятим калган балаларга наз һәм игътибар бирергә дә кирәк була.

– Ул көннәрне искә төшерсәм, адәм баласы түзсә түзә икән, дип уйлап куям. Берсеннән айнырга өлгермәгән дә идек бит. Тик ул чакта үзеңне уйлап тору юк, ничек тә 11 баланы да тигез күрергә, тигез итеп яратырга кирәк иде. Алдан әзерләнеп, тәвәккәлләп алган балалар түгел иде шул алар... Психологик яктан шактый гына эшләргә туры килде. Үз балаңны артыграк иркәләсәң, башкалар үпкәли, башкаларны иркәләсәң, үзеңнекеләр, дигәндәй... Әле ярый читтән кайткан түгел, килеп-китеп йөри торган балалар иде. Үзебезнекеләр әйбәт кенә кабул итте. Тиз арада бер яшьтәгерәкләре парлаштылар да бетеләр. Шөкер, бүгенгәчә шулай әле, – дип сөйли Гөлфирә апа.

Киң күңел

Асадуллиннар йортына кайтканда, балаларның өчесе зур була, шуңа да әниләрен югалтуларын алар аңлый.

– Ә кечкенәләре өчен әниләре әле дә җиләктә... Иң кечкенәсенә ул чакта өч кенә яшь иде шул әле. Үлгәнен аңлыйлар үзе, әмма көтәләр. Мин үзем дә апам һәм сеңлемне алып киткән авыруга каршы көрәшәм. Хастаханәгә киткән саен: «Син дә безнең әни шикелле үлмисеңдер бит?» – дип калалар. Югалтуның нәрсә икәнен белә шул балалар.

Бу сүзләрдән соң тамакка төер утырды. Мондый нык рухлы кешене моңарчы күргән юк иде... «Тормышны алып барырга, бу кадәр мал-туар тотарга көч каян аласыз?» – дип кызыксынам.

– Ә нишләргә соң? Бу кадәр баланы ашатырга да кирәк бит. Кайберәүләр, 18е тулуга, үз башын үзе карасын, дип фикер йөртә. Юк, без алай булдыра алмыйбыз. Ничек тә ярдәм итәргә тырышабыз. Алар бит атна саен диярлек кайтып та тора. Җыйнаулашып кайтсалар, килен-кияүләр белән 16 кеше булалар. Күңелең киң булса, барысына да өлеш тия, – ди әңгәмәдәшем.

Кайчандыр мәктәпкә бер йорттан 10 бала чыгып китсә, хәзер яннарында җидесе калган. Авылда яшәгәч, үзләрен башка балалардан ким күрмәсеннәр дип, район үзәгенә йөртеп кенә торалар икән. Кайсын кая, дигәндәй.

– Безнекеләр гел спортта булды инде. Кызларыбыз да көрәште. Өченчесе әле дә көрәшә. Авыл җирендә эш бик күп инде, ләкин гел мал арасында гына йөрмиләр, – дип сөйли Гөлфирә апа.

Хәзер инде барыбер җиңелрәк, ди ул. Иң зур һәм ихлас теләге – шушы балалар бәхетенә исән-сау булу. Без дә олы йөрәкле, көчле рухлы Гөлфирә апага сәламәтлек телик. Язмышына язылган иң олы сынавы артта калган булса ярар иде...

Лилия ГЫЙМАЗОВА



Зөлфия Хәлиуллина

Шаулап торсын!

Чүпрәле районының Иске Кәкерле авылында яшәүче Рөстәм Фәткуллинның үзенчәлекле шөгыле бар: ул җиз самавырлар җыя. Бүген аның коллекциясендә 27 төрле 38 самавыр бар.

– Мин аларны моннан ун ел элек, клубта эшләгән вакытта туплый башлаган идем. Ул вакытта мине узара салым программасы өчен җаваплы кеше итеп билгеләделәр. Кешеләргә кергәч, самавырларына күзем төшә башлады. Кызыгып киттем. Кемдәдер бик искесе була, кемдәдер ике булып, берсен кирәксезгә саныйлар. «Миңа кирәк!» – дим дә сатып алам. Балта остасы булып эшләгәндә, бер әби белән бабайның йортын сүткәндә бер самавыр килеп чыкты. Анысын да үземә алдым. Шулай итеп акрынлап коллекция тулыланды, – ди ул.

Бәяләренә килгәндә, алар төрле. Рөстәм Фәткуллинның коллекциясендә 70–80 мең сумлыклар да, 50–60 мең сумлыклар да бар. Үзе исә аларның кайсындыр 2–3 меңгә, кайсындыр 6–7 меңгә сатып алган. 500 сум түләп кенә кулга төшергәне дә бар. Тимер-томыр җыеп йөрүчеләрдән дә алып калганы булган. Самавыр эзләп, хәтта Казандагы «хәерче базары»на кадәр барып җиткән ул.

– Үземнең барысын да бергә исәпләп-санап караганым юк. Ә миңа миннән килеп сораучылар байтак булды. Бер кеше коллекциям өчен 700 мең сум тәкъдим иткән иде, бирмәдем. Монда эш акчада гына түгел, тарих бит болар. Аларны туплауга күпме хезмәт кергән. Һәркайсы аерым бер хис уятырга сәләтле. Сатар өчен җыймадым инде мин аларны. Алга таба, киресенчә, арттырырга, тагын да кызыклыракларын табарга телим. Иң беренче чыккан самавырларны эзләп караган идем, ләкин алары бик кыйммәт тора, – ди Рөстәм абый.

Еллар буе җыелган бу байлыгы тагын да зуррак булыр иде. Тик башта унбишләп самавырын сатып җибәргән икән. Менә шунда уйламыйчарак эш иткәненә үкенә хәзер үзе.

Рөстәм Фәткуллин туплаган самавырлар арасында моннан бер гасыр элек ясалганнары бар. Коллекциядә борынгы Баташев фабрикасы самавырлары да очрый.

Рөстәм абый әйтүенчә, аларның барысын да диярлек файдаланырга мөмкин.

– Элекке самавырларда иң беренче торба сыман җиренә агач күмере тутырыла һәм ул янган өлешендә су кайный. Аннан соң кечкенә чәйнеккә кайнар су агызасың. Самавырның өстенә куеп, чәй пешерәсең. Соңрак керосин, электр самавырлары барлыкка килгән. Хәзер бит инде күбрәк электр самавырлары гына кулланыла. Минекеләр барысы да күмер белән яга торган. Дөрес, арада эшкә ярамаганнары да бар. Аларын вакыт табып, бераз төзәткәләп алсаң, шулай ук рәхәтләнеп кулланырга була. Кунаклар килсә дә, үзебез генә булсак та, самавырда мәтрүшкәле, бөтнекле тәмле чәй кайнатабыз, – ди коллекция хуҗасы.

Зөһрә САДЫЙКОВА

САМАВЫРЛАР ТУРЫНДА КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР:

- 2008 елда Алабуга шәһәрендә самавырга һәйкәл куела. Аның биеклеге – 4 метр.
- Самавырлар бер-берсеннән тоткаларының, краннарының һәм төп өлешенең формалары белән аерылган. Иң киң таралганнары һәм арзанлылары булып банка рәвешендәгеләре исәпләнә.
- Дөньядагы иң зур самавыр 555 литр су сыйдыра һәм аңарда кайнаган судан 2220 кешегә чәй ясарга мөмкин.

ДИНӘ ЛАТЫЙПОВА:

«АЛЛАҺЫ ТӘГАЛӘ ГОМЕР БИРДЕ, ШУҢА ШӨКЕР ИТЕП ЯШИМ»

Алар гадәттә әңгәмәләрдә бергә катнаша, тамашачы да Динә янәшәсендә Рафаэль Латыйповның булуына күнеккән. Ләкин безгә бүген Динә ЛАТЫЙПОВА китап авторы буларак ачылды. Кулга каләм алуга ни этәргән? Китапларында – үз язмышымы? Иҗат аңа ни өчен кирәк? Без әнә шуларны белештек.

:: Буада төпләнеп, үз юлын тапкан, үз театрын ачкан Раил Садриев бар. Сез дә Рафаэль абый белән иҗатыгызны Буада башлап җибәрдегез. Нишләп шунда гына калмадык икән, дип уйлаганыгыз бармы?
– Һәр кешенең – үз сукмагы, үз юлы. Безнең дә Рафаэль абыең белән үзебезнеке, кеше юлыннан йөрмибез. Шуңа күрә Казанга килеп төпләнергә теләгәнбез икән, үкенмибез. Монда да үзебезне табарга, үз нигезебезне корырга насыйп булды.

:: Сезне халыкка чыгарган җыр кайсы?
– Мин күбрәк Рафаэльнең администраторы булдым, шуңа җыр мине түгел, Рафаэльне танытты дисәк, дөресрәк булыр. Шулай да халык безне Динә һәм Рафаэль Латыйповлар дип исендә калдырды. Беренче кассетабыз танылу китерде һәм анда кергән барлык җырлар халыкка барып җитте, дип әйтә алам. Шуннан соң инде һәр яңа программаның үз җыры булды. Әгәр үз җырың булып, халык күңелен яуламасаң, онытыласың, төшеп каласың. Шөкер, җырлар уңышлы булдылар, халык күңелен яуладылар. Моннан 30 ел элек җырланган җырлар бүген дә онытылмый. Мәсәлән, «Тәрәзәңдә утың бар» (Нияз Акмал сүзләре, Фәрит Хатыйпов көе), «Гомерләр үтә» (Роберт Миңнуллин сүзләре, Оскар Усманов көе) җырлары шундый.

:: Нәкъ менә сезнең язмышка тәңгәл җыр бармы?
– Җырда синең язмышыңның бер почмагы булса да чагылмаса, ул синең йөрәгең аша үтми. Йөрәк аша үткәрмәгәч, халыкка да барып җитми. Җыр йөрәктән, җаннан чыкканда, язмышыңа кайтаваз булып яңгыраганда гына озын гомерле була. Әйе, җырлар язмышыбызга тәңгәл дип әйтеп була.

:: Укучы сезне «Мәк чәчәге» әсәре аша да белә. Каләм алып язарга ни этәрде?
– Бер сөйләшеп утырганда гыйбрәтле язмыш тыңларга туры килде һәм менә шул кулга каләм алырга этәрде. Тәгәлрәге, башта ул пост рәвешендә социаль челтәрдә дөнья күрде. Әмма әйтәсе килгән фикерне бер пост белән генә тәгәлләп булмады, ул киңәйгәннән-киңәя барды. Укучыларда да кызыксыну уятты. Ниһаять, китап рәвешендә дөнья күрде. Шуннан соң инде мин әсәрләремне халыкка тәкъдим итә башладым. Интернет челтәрләрендә «Ата каз биюе», «Бер шакмак шикәр», «Төйнәлмәгән төер», «Бөкре мәхәббәте» дигән әсәрләремне тараттым. Һәр әсәрнең нигезендә чынбарлыктан алынган сюжет ята. Ул, әлбәттә, үзгәрә, әдәбиләшә. Бүген шушы әсәрләрнең берсе – «Бөкре мәхәббәте» дә китап булып чыгарга әзерләнә. Параллель рәвештә «Бүре сукмагы» дигән әсәрне язам. Аны да башта интернет аша тәкъдим итәчәкмен.

:: Сезнең бит үзегезнең язмыш та гыйбрәтле. Игезәк балалар табу, гаилә бөтенлеген саклау, чир... Болар хакында сөйләп үтсәгез иде. Ә иң мөһиме – авыр сынаулар алдында калганда ничек һәм кайдан көч алырга?
– Әйе, без ике игезәк кыз үстердек. Хәзер инде менә оныкларыбыз – малайлар үсеп килә. Тормыш бит ул, аның бураны да, җиле дә, челлә кояшы да кагылмыйча калмый. Бездә дә аның төрле чаклары булгандыр. Әмма гаиләне челлә кояшында янмыйча, яңгырында эреп акмыйча саклап калырга тырышасың. Хәзер барысы да Аллага шөкер, менә шунысы – иң мөһиме. Әйе, сәламәтлек какшаган чаклар да булды. Ул чакта үз-үзеңә ышанычтан бигрәк, синең тирәңдәгеләрнең өметышанычы көчле булу кирәктер. Терелер өчен ничек тә өметне сүндермәскә кирәк. Тирә-юньдәгеләр көчеңә ышанса, синең дә өметең ныгый. Минем янәшәмдә ышанычлы терәгем, таянычым булды. Миңа Рафаэль бик нык ярдәм итте. Нәкъ яу кырындагы кебек булды ул. Рафаэль мине саклап калу өчен бөтен көчен куйды. Халык медицинасын да кулланды, табибларга да йөртте. Аллаһы Тәгалә гомер бирде, шуңа шөкер итеп яшим.

> Ә иҗат – тормышыбызның бер өлеше. Җыр, шигърият, сәхнә – без әнә шулар белән яшибез. Язуга килгәндә, ул – минем күңел халәте. Анда әсәреңнең герое белән бергә-бер каласың, алар белән яшисең, сөйләшәсең, бәхәсләшәсең.

:: Сез – бик күп никах һәм туй тантаналарын алып баручы да. Менә шул чараларда ук бу гаилә озын гомерле булыр, яки киресенчә, ай-һай, озак яшәмәсләр, дип фаразлый аласызмы?
– Әйе, без кырык елга якын менә шундый матур чараларда катнашабыз. 1987 елда беренче туйны алып барган идем. Шуннан бирле бик күп туйлар, бик күп никахлар күрергә туры килде. Вакыт белән яшьләр дә, тәрбия дә үзгәрә. Аларны үзең белән чагыштырып бәя бирергә ярамый. Яшьләр тормышка әзерлекле, гаилә кору кебек олы эшне дә аңлап башкаралар. Шул ук вакытта гаилә камытын бик үк әзер булмаган килеш кигәннәре дә очраштыргалый. Андыйлар күзгә чалынса, «И балакай, сиңа холыкны формалаштырырга кирәк шул әле», – дип уйлап куясың. Без уздырган туйлар, без кавыштырган гаиләләр, 100 проценты ук дип әйтмәсәм дә, 90 проценты тулы гаилә тормышы белән яши. Без алар белән барыбер сирәк булса да аралашабыз. Хәзер инде күбесе үзләре әби-бабай, кода-кодагый булып беттеләр. Күбесенең балаларының туйларында чыгыш ясыйбыз, юбилейларында катнашабыз.

:: Бәхетле гаилә төзү рецепты бармы?
– Аның рецепты бер: түземлек, сабырлык, җаваплылык кирәк. Шулар булганда, бар да яхшы була.

Блиц сораштыру

– Иң бәхетле мизгел?
– Тормышымның һәр мизгелен бәхет дип саныйм. Таңның яктылыгына сөенеп уянып, үз аякларыңда йөреп китү, дөнья матурлыгын күрү, тою, ишетү һәм шуларга шөкер итеп яшәү – бәхет инде ул. Дөньялар тыныч булсын, кайгы-хәсрәтләр килмәсен, көтелмәгән сынаулар капка ачып кермәсен иде.
– Иң авыр мизгел?
– Якыннарымны югалткан көннәр... Ике абыем яшьли китеп барды. Юкса бит ир уртасы булып тормыш итәр чаклары иде.
– Хатын-кызга каршы эшли торган сыйфат?
– Үз-үзеңне яратмау. Беренче чиратта хатын-кыз үзен яратырга тиеш. Ә без беренче урынга тормыш итүне куябыз.
– Ир-атка килешми торган сыйфат?
– Буш сүзлелек, вәгъдәсезлек.
– Иң зур теләгегез?
– Иманлы булып, намазлыкта, балаларымның миһербан-шәфкатенә сөенеп, бәндәләргә мохтаҗлык төшермичә, илгә-көнгә тынычлык биреп, пар канат булып гомер итсәк иде дип телим.

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

АЙГӨЛ ӘХМӘТГАЛИЕВА

ТУЗГАНАК КЕРФЕГЕ

< Дәвамы. Башы 14, 21 июль саннарында

– Бәйләмәсәң, янган мичкә дә, казанга да сикерә бит алар, кызым, – ди әнкәсе.

Шулайдыр да, барыбер кызганыч үзләре. Җитмәсә, бертуктамый бәәлдиләр. Өч кәҗә абзарда, бик салкын көннәрне аларны да өйгә алып керәләр. Шулар турында язар иде Гөлсәйдә. Сәетнең, этисеннән калган бөтен караны мәктәпкә алып китеп, укучыларга бирүен әйтер иде микән? Дәфтәрләрне дә таратып бетергән. Хәзер менә үзе китап арасындагы юлларга чөгендер карасы белән язып интегә... Ярар инде, болары турында этисенә әйтеп тормас, әллә ничек, абыйсын әләкләгән шикелле булыр.

Кыз шулай этисе белән хыялында гына сөйләшә-сөйләшә, уйларында аңа көн саен хат яза. Гөлсәйдә, буе орчык хәтле генә булса да, бик тере, чая. Этисе ягына охшап, кашлары да, керфекләре дә чем-кара үзенең, үзбәк кызыныкыдай озынча күзләре каракучкыл түгәрәк йөзенә гел ниндидер шаянлык сирпеп тора, юка кара чәче, уртадан юл сабып, ике толымга үрелгән. Дөрес, үзе генә аергач, аның чәч юлы әнисенеке кебек тип-тигез, туп-туры булып ачылмый, аркылы-торкылырак килеп чыга. Менә әнисе чибәрләрнең чибәре ичмаса. Шикәр кебек ак тәнле, ак йөзле; күзләре кояш яктысында әле күгелҗем, әле зәп-зәңгәр, кичке эңгердә ямь-яшел төстә күренә. Иреннәре дә Гөлсәйдәнеке кебек нәзек җептәй җәелмәгән – чәчәк таҗыдай өскә кайтарылып, уймак тиклем генә булып тора. Уклау йоткандай төп-төз, озын, зифа буена, биленә төшеп торган озын чәчләренә сокланмас җиреннән сокланырсың. Тик менә этисеннән калган олы бушлатны, каладан алып кайткан алагаем зур итекне киеп, чәч-башын мамык шәл белән томалап эшкә чыгып киткәч, аның артыннан Гөлсәйдә елардай булып карап кала – бар булганы белән күрше хатыннарына охшый да бетә әнисе. Бөтен сылулыгы өч Хәдичә сыенырлык бушлатка керә дә югала... Сәет абыйсы да әнисе ягына тарткан: ул да ак тәнле, зәп-зәңгәр күзле. Буйга озын, бигрәк ябык үзе. Соңгы араларда туя ашау әллә ни тәтемәгәч, тагын да чандырланып китте. Гөлсәйдәне ярата ул, апаем дип кенә тора. Дәрес әзерләгәндә ачуын китерсәң генә: «Тай моннан, Гөлсәй», – дип пырылдатып куып җибәрә.

Шушы елның кышында, авыл халкының тормышына беркадәр яңалык өстәп, Усайга Ленинградтан эвакуация белән ике марҗа килде. Аларны иске ферманың каравыл өенә урнаштырдылар. Катерина дигәне – аны халык беренче көннән үк Кәримә дип кенә йөртте – кып-кыска аксыл чәчле, керфекләре гел өскә кайтарылып торган зур зәңгәр күзле, озын буйлы, ябык кына яшь хатын иде. Зинаида дигәне, киресенчә, чегәнгә охшаганрак: күзе-кашы кап-кара, борынында олы гына миң шәйләнә, озын кара чәчен ниндидер тимерләр белән баш очына җыеп, кабартып куя. Үзе, ничә ишетсәң, борын астыннан гел бер үк моңсу көйне шыңшып йөри. Бала-чага аны Зина түтәй дип йөртергә гадәтләнде. Зина түтәйнең биш-алты яшьләрдәге Лена атлы кызы бар иде. Бер оч балалары Шәмсия, Зәйнәп, Гөлсәйдә, Асия, шул кызны күрер, аның белән танышыр өчен, ферма тавына кадәр тау шуарга килә башладылар. Чана дигән нәрсә берсендә дә юк, кемдә – казан капкачы, кемдә – иске тас. Биек тау өстенә аһылдап-ухылдап менеп җитүгә, иң беренче эш итеп, каравыл өенә күз салалар: янәсе, күреп-кызыгып, теге кызый үзе чыкмасмы? Ят кеше булгач, танышасы, сөйләшәсе килә бит. Сөйләшәсе дип, ул татарча, кызлар урысча белми анысы. Шулай да ничек тә аңлашырлар иде әле.

Беркөнне кызлар көрткә бата-чума тауга күтәрелүгә, каршыларына кызын җитәкләгән Зина түтәй килеп чыкты. Ул кызның матурлыгы! Курчак та курчак, бу кыз да курчак. Өстендә – авыл балаларының төшенә дә кермәгән кып-кызыл пәлтә, башында фәсле кара башлык. Аягында исә... Әнекәем! Мондый калын табанлы, әллә эт, әллә песи йоны кебек күпереп торган итекне гомерләрендә дә күргәннәре юк иде – кызлар, авызларына су капкандай, шым булып катып калдылар. Хәтта исәнләшергә дә оныттылар.

Зина апа, ап-ак тигез тешләрен күрсәтеп елмайды да үз телендә нидер сөйләп алды. Әкәмәт димә, аның ни әйткәнен аңладылар бит! «Лена да сезнең белән тау шусын әле», – диде!.. Хәер, алай дидеме, юк микән, тик кызлар аны нәкъ шулай кабул итте. Каян кыюлык килгәндер – ятсынуны, кыенсынуны онытып, Гөлсәйдә Ленаны җитәкләп тә алды, үзе шуа торган капкачка төртеп күрсәтә-күрсәтә, шуып төшәргә әйдәкли дә башлады.

Бу кыз да алардан әллә ни аерылмый икән: таудан җилдереп төшкәндә чыркылдап-чыркылдап көлә, бау тагылган казан капкачын биек таудан өстерәп менгәндә аһ-ух килә, үзе, җитмәсә, бертуктаусыз «мама» дип эндәшә-эндәшә, Зина апага кул изи. Күрәсеңме мине, дип мактануы инде. Шул көнне Гөлсәйдә әни дигән сүзнең урыс телендә «мама» булуын белеп кайтты.

Өйләргә таралышканда, барысы да шау-гөр килеп, берсен-берсе бүлдерә-бүлдерә, үзләре откан урыс сүзләрен кызык итеп кабатлап, көлә-көлә кайттылар. Асия генә авыз-борынын турсайтып, бер сүз дәшми, үзалдына атлады. Баксаң, ул Гөлсәйдәнең, ахирәте турында онытып, әллә нинди чит бер кыз белән дуслашуына үпкәләгән икән.

Дөрес, тора-бара Лена кызлар арасында тәмам үз кешегә әверелде, ул инде әнисеннән башка да алар янына тау шуарга чыга башлады. Шәмсиянең Шурага, Зәйнәпнең Зояга, Асиянең Асяга, Гөлсәйдәнең Гуляга әйләнүе дә үзара рәхәтләнеп көлешергә сәбәп булды. Зәйнәп, каян башына килгәндер, Ленаны «кит әле, бәйләнмәле» дип әйтергә өйрәтте. Янәсе, кем генә килеп, ни генә әйтсә дә, шулай дип кенә җавап кайтар... Бу сүзләрне Лена шундый матур, йомшак итеп кабатлый, кызлар кар өстендә тәгәри-тәгәри, тагын җан рәхәте белән көлешәләр.

Лена нишләптер Гөлсәйдәне аеруча дус күрде. Тик кызларның аралашуы артык озакка бармады. Ничек тиз дуслашсалар, шулай ук тиз хушлашып та куйдылар. Юк, Лена әнисе белән авылда яшәвен дәвам итте, тик Гөлсәйдә генә, бер вакыйгадан соң, кыш беткәнче бүтән ул тирәгә тау шуарга аяк басмады...

Беркөнне әнисе бәкегә кер чайкарга төшкәндә, Гөлсәйдә дә ияргән иде. Зина түтәйнең каяндыр кайтып килеше икән, алар янына туктап исәнләште дә ачык елмаеп, Хәдичәгә озак кына нидер сөйләргә тотынды. Кулындагы кечкенә капчыгына да төртеп-төртеп күрсәтте. Хәдичә урысчаны беркадәр сукалый иде, аңлаган кыяфәттә баш селкеп торды да Гөлсәйдәгә эндәште:

– Зина апаң үзләренә кунакка чакыра, Ленага күңелсез, бергә уйнарлар иде, ди. Барасыңмы?

Һи, шулай дип чакырып торганда бармыйлар димени?.. Берсенә ике аягы сыярлык алагаем зур киез итекләр белән карны шыгырдата-шыгырдата, Гөлсәйдә, Зина апа янәшәсеннән атлап, кунакка китте.

Каравыл өенең бүрәнәләре каралып беткән, тыштан бик шыксыз күренә. Эче алай котсыз түгел түгелен: ялтырап торган тимер башлы өч карават, зур авызлы ап-ак мич, шул мич башында сандыкка охшаган берничә тартма (алары чемодан дип атала икән, Зина апасы Гөлсәйдәнең шаккатып карап торуын күргәч, шулай диде) шәйләнә. Аяклары кыршылып беткән дүртпочмаклы өстәлгә бик матур челтәр ашъяулык ябылган. Монда Зина, Лена һәм күршеләре Катерина-Кәримә өчәүләп яшиләр.

Зина Гөлсәйдәне ияртеп кайтып кергәндә, Лена, пыр тузып, сиртмәле караватта сикерә, иңбашына чуклы озын шәл салган Катерина исә, ыргакка охшаган озын энә тотып, кап-кара җептән нәрсәдер бәйләп утыра иде. Ишек ачылуга, аларның икесенең дә күзе иң башта кунак кызына түгел, Зина кулындагы кечкенә капчыкка төбәлде.

– Колхоздан бераз он бирделәр. – Зина капчыкны саклык белән генә өстәлгә куйды, шуннан соң Гөлсәйдәгә ымлап: – Леночка, күр әле, кемне алып килдем?! Икәүләп рәхәтләнеп уйнагыз. Гулечка, өстеңне сал, балакаем, оялып торма, – дип, кызның кулындагы зур бияләйләрне үзе үк салдырырга тотынды. – Хәзер мичкә ягып җибәрәм, крендель пешерәм, – дип сөйләнә-сөйләнә, тиз-тиз генә пәлтәсен салып, мич аралыгындагы кадакка элде, Гөлсәйдәнең пәлтәсе белән бияләен, йомарлам итеп төреп, избыт* өстенә куйды.

– Кирәк дисәгез, мин дә булышырмын. – Катерина шөгыленнән бүленми генә Зинага эндәште.

– Утыр, утыр, үзем җитешәм!

Гөлсәйдә аларның теттереп урысча гына сөйләшүләреннән башта шомраеп торса да, бераздан инде дөньясын онытып, Лена белән караватта сикерергә тотынды.

Катерина урыныннан кыймылдап, карават астына иелде, андагы кечкенә тартмадан кып-кызыл төстәге киез эшләпә тартып чыгарды, аны бик озак кына күкрәгенә кысып торды да көтмәгәндә әлеге кечкенә эшләпәне Гөлсәйдәгә сузды.

– Это тебе, доченька, мой небольшой подарок, – диде дә үзе башын иеп бәйләменә тотынды.

Көтелмәгән бүләктән аптырап калган Гөлсәйдә, авызын ачар-ачмас, кыенсынып кына «рәхмәт» диде дә бүләкне сырма кесәсенә илтеп салды.

Ике кызның чыркылдашуына башын күтәрми генә колак салган Катерина, бәйләмен итәгенә куйган килеш, бик озак бер ноктага текәлеп утырды да, кинәт мышкылдап елап җибәрде. Шундый ук кинәтлек белән сикереп торды, иңсәсендәге шәлен башына бөркәнде, ишек буендагы сырманы култык астына кыстырды, зур аксыл киез итекне аягына элеп, өйдән чыгып та йөгерде.

Моны күргән Гөлсәйдә, үзен гаепле хис итеп, шым гына караваттан төште, аяк очы белән идәнгә рәсем ясагандай, берара сүзсез утырды.

– Катя апаның биш яшьлек кызын немецлар үтергән. Ленинградтан чыгып килгәндә. Шуңа ул гел елый. – Зина, йомычкага ут элдереп маташкан җиреннән, артына борылмый гына, татарча сүзләр дә кыстыра-кыстыра, Гөлсәйдәгә шулай дип аңлатырга тырышты.

*избыт – диал., мич кашагасы

Дәвамы бар >

Шигърият

Гөлүсә ШАҺБАН

ТАҢНАР, ТАҢНАР...

Җил тузгыткан чәчләремдә кайчак
Күрсәгез сез көмеш төсләрен,
Мин әзермен шатланып-сөенеп
Каршыларга гомер көзләрен.

Яшьлегемне өзелеп сагынганда,
Хәтер сукмаклары һәрчак ачык.
Мин сәяхәт итәм яшьлегемә,
Гашыйк булган елларыма, качып!!!

Әйе, качып, чөнки үзем өчен
Беркем белмәс анда серләр ята.
Шул серләргә шаһит булган берәү...
Әнә сызылып кына алсу таң ата.

Әй ул таңнар... Алсу таңнар белән
Күпме серләрне без бүлештек.
Таңнар белән күпме яшьләр койдык,
Сөештек без, шашып көлештек.

Таңнар, таңнар... Алар һаман алсу...
Офыкларга барып тоташа.
Әйтерсең лә яшьлекләргә юллар –
Алсуланган офыклар аша.

Мәхәббәттән шашып сөйгәндә дә,
Югалтудан янып көйгәндә...
Яңа көнгә таңнар юл күрсәтте
Тормыш яме бетте дигәндә.

Ничә тапкыр таңны каршыладык...
Күпме серләр сыйган таңнарга!
Алсуланып аткан таңнар кирәк
Гашыйк җанның күңелен аңларга.

Төннәр буе күз дә йоммый кайчак
Зур өметләр белән таңны көттек.
Алсуланып аткан таңнардан соң
Бәхет тулы көнгә өмет иттек.

Таңнар, таңнар... Көннең азагымы
Әллә башы туар көннәрнең?
Таңнар белән уртак булган серләр
Юк икән ул, белмим, кемнәрнең?

Таңнар, таңнар... Алар һаман алсу...
Офыкларга барып тоташа.
Әйтерсең лә яшьлекләргә юллар –
Шушы алсу офыклар аша.

БЕРКАЙЧАН ДА, МИН БӘХЕТСЕЗ, ДИМӘ

Беркайчан да, мин бәхетсез, димә.
Гомерләрең син дигәнчә үтмәсә дә,
Эшләреңдә гел уңышлар көтмәсә дә,
Кайчагында ашарыңа җитмәсә дә,
Мин бәхетсез, димә!
Беркайчан да, мин бәхетсез, димә!

Якыннарың бер көн ташласа да,
Гомер юлың өр-яңадан башласаң да,
Килеп әгәр өсләреңә таш яуса да,
Мин бәхетсез, димә!
Беркайчан да, мин бәхетсез, димә!

Авырлыктан сынсаң, сыгылсаң да,
Ялгыш кына абынып егылсаң да,
Күз яшеңә буылып тыгылсаң да,
Мин бәхетсез, димә.
Беркайчан да, мин бәхетсез, димә.

Җан дусларың сине сатса да,
Ашларыңа ташлар атса да,
Тормышыңны ятлар ватса да,
Мин бәхетсез, димә.
Беркайчан да, мин бәхетсез, димә.

Кояш әгәр нурын тигез сипсә,
Җир йөзендә яшәр өчен урын җитсә,
Мин бәхетсез, димә.
Хакың юк!

Декретта күзәтүләр

Уены-чыны бергә

- Балагыз хәзер йөгереп арыр дип уйлыйсыз икән, чыннан да арыр. Әмма сездән соң.
- Сабыегызга аерым карават сатып алу – әрәм акча. Барыбер сезнең белән йоклаячак.
- Әгәр дә сезгә бала кәкәй иткән кебек тоела икән, димәк, дөрес тоела. Тикшереп тә тормагыз.
- Сабыегыздан бераз ял итеп торасыгыз килсә, кунаклар чакырыгыз. Бергә мәш килсеннәр.
- Бәдрәфтә ябык ишек белән утырасыгыз килә икән, утсыз утырачаксыз.
- Елау арасында пауза никадәр зуррак – киләсе елау шулкадәр катырак булачак.
- Уенчыклар савыты үтә күренмәле булса уңайлы. Бозыла башлаган ризыкларны күрер өчен.
- Балага таудан ничек төшәсен бер тапкыр күрсәтсәгез, билсез калачаксыз.
- Өйдән чыкканда документларыгызны тикшерегез. Паспортыгыз уенчыклар арасында булырга мөмкин.

Әз-мәз мәзәк

Инде берниндИ чыгу юлы калмады, дип уйлыйсыз икән, «Титаник» корабы ресторанЫ аквариумындагы омарларны күз алдыгызга китерегез.

* * *

Йөзем яратсагыз, почта аша үзегезгә виноград җибәрә аласыз.

* * *

– Матурым, сарыклар уртача алганда ничә ел яши икән?

– Ни булды? Авырып киттеңме әллә?

Сканворд җаваплары

Горизонталь: Вәсим, олы, нәшир, Рамазан, гариза, унҗиде, Ревва, Замирә, Римма, изгелек, Фа, Ралиф, авылдаш, Эдуард, мә, як, Макрон, Ян, иза, он, әйт, ашчы, Уел, Ауди, каршы, Гөлназ, идән, чү, Ирина, ни, ар, дума, ки, Ароче, Нил, Рав.

Вертикаль: гозер, морг, Алан, Рамил, ул, иярчен, Зариф, Ла, Венера, әз, энә, зиндан, гид, йа, РИУ, сишәмбе, уяту, мал, Вилдан, диндар, Морозов, Аида, Ор, аркадаш, акча, кылану, Нуриев, ымлык, Җәмилә, ач,ияру, до, Фаяз, кашкарый.

Сәхифәне Данил СӘФӘРОВ әзерләде



Беләсең килсә...

1 Ябалак көтүен ничек атыйлар?

а) федерация;
б) секретариат;
в) парламент.

2 Бәллүр нәрсәдән эшләнә?

а) кургаш;
б) көмеш;
в) бакыр.

3 «Монтенегро» дип кайсы илне атыйлар?

а) Алжир;
б) Черногория;
в) Мексика.

4 Номофобия нәрсә ул?

а) телефонсыз калудан курку;
б) кырмыскалардан курку;
в) кояшта кызудан курку.

Җаваплар: 1. в); 2. а); 3. б); 4. а).

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар: ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 14042 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 307

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәррирнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.)**.

16+